БАЛЫКЧЫ ФӘЛСӘФӘСЕ

Балык тотуның рәхәте нидә?

> 6



САЛЫМ ТҮЛӘГӘН

өчен акчаны кайтару турында 10 сорауга җавап

> 7

АЛЕКСЕЙ АРЗАМАЗОВ:

«12–13 тел беләм, иң яратканнарымның берсе – татар теле»

> 15

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 20 (28793) | Җомга | 11 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

КӨТЕЛМӘГӘН БҮЛӘК

МИНИ-ТРАКТОР ИЯСЕНӘ БАРЫП ҖИТТЕ

«Бөтен авыл өчен зур вакыйга булды бу!» «Ватаным Татарстан» газетасына язылучылар арасында уйнатылган мини-тракторны иясенә тапшырырга баргач, Смәел авылы халкы шулай диде. Инде хәбәр иткәнебезчә, «Уралец» сәүдә компаниясе белән берлектә әзерләнгән бүләгебез Балтач районының Смәел авылында яшәүче Фаварис Галиевка чыкты. Узган атнада без анда кунакта булып кайттык.

> 5

Ишетми калмагыз

Тагын бер начар рекорд

Соңгы тәүлектә Татарстанда коронавирус йоктыручылар саны буенча яңа антирекорд куелган: барлыгы 1725 кеше чирләгән. Шуның 101е – балалар. Сәламәтлек саклау министрлыгы матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, 246 сырхау хастаханәгә салынган, 1479ы өендә дәвалана. Иң күп чирләүчеләр Казанда (1190 кеше) теркәлгән. Чаллыда – 126, Алексеевск районында – 41. Барлыгы 36 муниципалитетта чир иярту очраклары ачыкланган. Шул рәвешле, соңгы мәгълүматлар буенча, пандемия башланганнан бирле республикада инфекция йоктыруның 60489 очрагы теркәлгән. Барлыгы 2427942 кеше прививка ясаткан. 211909 кеше ревакцинация узган.

Сүз уңаеннан, Россия Хөкүмәте февраль һәм март аеның беренче яртысына «больничный»лар түләүгә өстәмә рәвештә 76,5 миллиард сумнан артыграк күләмдә акча җибәрәчәк. Бу хакта Премьер-министр Михаил Мишустин белдергән. Өстәмә акча бирү, чирнең көчәюе сәбәпле, кешеләрнең «больничный»га күбрәк китә башлавына бәйле.

БДИда – үзгәрешләр

Быел Бердәм дәүләт имтиханында чираттагы үзгәрешләр пәйда булачак. Мәгълүматны анализлауны, шулай ук мәсьәләне төрле ысуллар белән чишүне таләп иткән биремнәр күбрәк булачак. Рособрнадзор башлыгы Анзор Музаев әйтүенчә, 2022 елда математика буенча имтиханда кайбер гади биремнәр катлаулырakларына алыштырылачак. Имтиханны, пандемиягә кадәрге чорда ничек үткәрелгән булса, шулай үткәрү күздә тотыла. «2020 елда вузга керүчеләр генә БДИ тапшырды, калган укучыларга аттестация нәтиҗәләре буенча аттестат тапшырылды. Ә 2021 елда вузга керергә планлаштырмаучылар элеккечә – дәүләт чыгарылыш имтиханын бирде», – дип искә төшереп үткән ул.

Яңа һөнәргә өйрәтәләр

Россиядә яңа һөнәргә бушлай өйрәтү һәм өстәмә белем бирү программасы киңәйтелә. Әлеге максатка 1,2 миллиард сум күздә тотылган, дип хәбәр итә Хөкүмәтнең телеграмм-каналы. Шулай итеп, быел 150 меңләп кеше яңа һөнәргә өйрәнә алачак. Иң элек 35 яшькә кадәрге һөнәрсезләргә өстәмә белем алу яки кирәклерәк һөнәргә өйрәнү мөмкинлеге биреләчәк. Армиядән соң яки укуын тәмамлагач, 4 айдан озаграк эш таба алмаучыларга да кагыла бу. Моңа кадәр 50 яшьтән өлкәнрәкләрне һәм яшь аналарны һөнәргә бушлай өйрәтү программасы гамәлдә иде.

Районнарда ни хәлләр?

Мамадыш

Түбән Ушма авылында гомер итүче Бөек Ватан сугышы ветераны, тыл хезмәтчәне Фатыйма Насыйбулла кызы Шаһивәлиевага 101 яшь тулды. Туган көнендә аның янына район башлыгы Анатолий Иванов һәм авыл җирлеге башлыгы килде. Фатыйма Шаһивәлиева 1921 елда Түбән Ушмада туган. Сугыш башланганда, ул нибары 20 яшьлек кыз була. 27 яшендә якташы Әхмәтгали Шаһивәлиевка кияүгә чыга. Егет хәрби булганга күрә, яшь пар гаилә тормышларының беренче 9 елын ил буйлап сәяхәт итеп үткәрә. Шаһивәлиевләр туган авылларына өч бала белән кайтып керә, аннан гаиләләрен тагын биш бала тулыландыра. Бүген Фатыйма апа улларының берсе белән яши. «Күзләрем начар күргәч, өй тирәсендә ни дә булса эшләү кыен», – ди ул.
(«Мамадыш-информ»)

Әлки

Әлки районында сыерларның буаз булу-булмавын хәзер УЗИ-сканер ярдәмендә тикшерәләр. Күптән түгел район ветеринария берләшмәсенә әнә шундый аппарат кайтты. Әлеге хезмәттән утызлап сыер һәм ат хуҗасы файдаланып өлгергән. Тикшерүләр һәр унынчы терлекнең кысыр булуын ачыклаган. Районның баш ветеринария табибы урынбасары Илшат Хәйретдинов әйтүенчә, УЗИ тикшерүен башкару өчен, ике ветеринарны укытып кайтарганнар. Терлекләрне УЗИ ярдәмендә ветеринария табиблары Рафикъ Кәримов һәм Рәшит Гайнетдинов тикшерә.
(«Әлки хәбәрләре»)

Питрәч

Татарстанның иң зур авылларыннан берсе булган Шәледә танылган татар рәссамы Харис Якуповка багышланган музей ачарга җыеналар. Музейны даруханә бинасында ачарга ниятлиләр. Даруханә исә Шәле дәвалау амбулаториясе бинасына күченәчәк. «Быел Шәледә музей комплексы булдырырга уйлыйбыз. Авылда 1895 елда төзелгән агач мәчетне төзекләндерү эшләре башкарылачак», – диде район хакимиятенең матбугат сәркатибе Ләйсән Мифтахова. Шәледә этноавыл комплексы төзү нияте дә бар.
(«Татар-информ»)

Зәй

Быел Зәй үзенең 370 еллыгын билгеләп үтә. Зәйнең «Алтынчәч» балалар бакчасы тәрбиячеләре Лариса Мөхетдинова һәм Рания Уразайкина «Минем яраткан шәһәрем – Зәй» дип исемләнгән методик кулланма чыгарган. Әсбап бакча педагоглары өчен махсус эшләнгән. «Безнең өчен кече Ватан ул – Зәебез. Кече Ватан – якыннарыбыз һәм кадерле кешеләребез яши торган урын. Без балаларга моны кечкенәдән төшендерергә тиеш, дип саныйбыз», – ди Рания Уразайкина. «Бу методик кулланмада безнең Зәй турында мәгълүмат тупланган. Төрле яшьтәге балалар өчен ике телдә күңел ачу, шөгыльләнү конспектлары, Зәй шәһәре турында шигырьләр бар. Шулай ук шәһәр турында сканвордлар, кроссвордлар күрергә мөмкин», – дип аңлатты Лариса Мөхетдинова.
(«Зәй офыклары»)

ПОЛИЦИЯГӘ ЭШ КИМЕМИ

Нәтиҗә

Ришвәт күләме 330 мең сумга җиткән, IT-җинаятьчелек 3 тапкыр арткан, полициядә 10 урынына 9 кеше генә эшли. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгында узган елга нәтиҗә ясадылар. Быел беренче мәртәбә утырышка журналистларны чакырмадылар. Сәбәбе – коронавирус. Шуның аркасында хокук сакчыларының эше дә арткан.

tatarstan.ru

Узган ел республика полициясе, эпидемиологиягә каршы таләпләрнең ничек үтәлүен ачыклау өчен, кеше күп җыелган урыннарда – меңнән артык, сәүдә, туклану оешмаларында, транспортта, тамаша һәм күңел ачу чараларында 400 меңнән артык тикшерү уздырган. Нәтиҗәдә 187 мең беркетмә төзелгән. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының коллегия утырышында генерал Артем Хохорин әнә шундый саннар китерде. Аңлашылганча, бу – хокук сакчыларына замана чире аркасында йөкләнгән өстәмә мәшәкать. Төп эшкә килгәндә, былтыр эчке эшләр органнарында 51933 җинаять теркәлгән. Шуның 15534е – авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр категориясенә керә. Министр үз чыгышында соңгы дүрт елда тәүге тапкыр җинаятьчелекнең кимегәнен, үтерү, сәламәтлеккә куркынычлы зыян китерү, талау кебек очракларның азайганын әйтте. Узган елгы күрсәткечләр турында сөйләгәндә, аеруча авыр җинаятьләрнең тулысынча диярлек фаш ителгәнен искәртте. Әйтик, үтерү очракларының 98 проценттында гаепле кеше табыла, ә бу – соңгы 26 елдагы иң зур күрсәткеч икән.

Генерал Хохорин республикадагы оператив вазгыятьнең контрольдә булуын әйтте. Әмма авырткан урыннар да бар. Аларга коллегия утырышында катнашкан Президент Рөстәм Миңнеханов та игътибар итте. Әйтик, замананың тагын бер чиренә әверелгән IT-җинаятьчелеккә аерым тукталдылар. Узган ел Татарстанда мәгълүмат һәм телекоммуникация технологияләре ярдәмендә кылынган 17574 җинаять теркәлгән. Шуларның 8687се – мошенниклык, 5514се банк счетыннан акча урлауга бәйле. Мондый җинаятьләр арасында законсыз наркотик сату, компьютердагы мәгълүматны урлау очраклары да бар. Соңгы 5 елда IT-җинаятьчелек 3 тапкыр диярлек арткан. Ә гаепләрне фаш итү күрсәткече 25 проценттан артмый. Министр әйтүенчә, быелның 3 аенда гына да Татарстанда яшәүчеләр мошенникларга 100 млн сум акча күчергән. Генерал Хохорин, мондый очракларга каршы көрәшү өчен, журналистлар һәм район башлыклары ярдәменә өметләнә. Татарстан Президенты исә полиция хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын арттырырга, заманча технологияләрдән файдаланырга, банк берләшмәләре, интернет-провайдерлар, кәрәзле элемтә операторлары белән хезмәттәшлекне җайга салырга киңәш итте. Халыкның финанс аң-белемен күтәрү дә комачау итмәячәк.

Акча димәктән, Рөстәм Миңнеханов икътисадны криминалдан арындыру һәм коррупция мәсьәләсенә дә аерым тукталды. «Ришвәтчелек, бюджет акчасын урлау фактларын активрак ачыкларга һәм шул исәптән илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаны дөрес кулланмауны булдырмый калырга, капиталны чит илгә законсыз чыгару омтылышларына каршы катгый чара күрергә кирәк», – диде ул. Ә министрлык саннарына ышансаң, узган ел Татарстанда 2095 икътисади җинаять ачыкланган. Дәүләт хакимияте һәм дәүләт хезмәте мәнфәгатьләре, ягъни коррупциягә бәйле 765 җинаять теркәлгән. Шулардан 613е – ришвәтчелек. Ришвәтнең уртача күләме 330 мең сум булган.

Рөстәм Миңнеханов утырышта экстремизмга каршы көрәшкә дә зур игътибар бирергә кирәклеген әйтте. «Яшьләрне деструктив төркемнәргә җәлеп итү мәсьәләсе бездә аеруча борчу тудыра», – диде Президент һәм интернеттагы хәлләрне күзәтеп барырга, вакытында чара күрергә кушты. Артем Хохорин, үсмерләр арасындагы җинаятьчелек турында сөйләгәндә, бу эш өчен барлык шәһәр-район бүлекләрендә төзелгән «Лидер» төркеменең нәтиҗәле булуын әйтте. Узган ел Татарстанда үсмерләр җинаятьчелеге 20 процентка кимегән. Хокук сакчылары 3513 рейд уздырган, 191 административ беркетмә төзелгән, 45 җинаять эше ачылган, шикле 212 яшьләр төркеме ачыкланган. Вакытында чара күрелмәүнең нәрсәгә китергәнен узган гасырның 90 нчы елларында күрдек. Оешкан җинаятьчелек куркынычы хәзер дә юк түгел. Һәрхәлдә, узган ел республикада мондый төркемнәрнең 823 әгъзасы җинаять җаваплылыгына тартылган, алар тарафыннан кылынган 1293 җинаять фаш ителгән.

Татарстан Президенты наркотикларга каршы көрәштә зур эш башкарылганын әйтте, миграция мәсьәләсендә игътибарлы булырга кушты һәм юл иминлегенә аерым тукталды. Былтыр Татарстан юлларында аварияләр саны да, корбан һәм имгәнүчеләр дә кимегән, әмма Президент канәгать түгел. «Гыйнвар аендагы вазгыять борчу тудыра. Без инде сары зонада түгел, ә кызыл зонада. Кемне дә булса гаепләргә тырышмыйм, бу – безнең уртак эшебез. Бу эштә барлык министрлыклар һәм ведомстволар катнашырга тиеш, иҗтимагый оешмаларны да җәлеп итәргә кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Мәшәкать күп, вазгыять катлаулы булса да, Татарстанның полиция хезмәткәрләре дөрес, тәгәл һәм өзеклексез эш иткән. Президент хокук сакчыларының хезмәтен әнә шулай бәяләде. Шул ук вакытта эчке эшләр органнарында кадрлар кытлыгы 12 процентны тәшкил итә. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, бу мәсьәләне хәл итү өчен, конкрет чаралар күрергә, әйтик, хезмәт хакын арттырырга кирәк. Президент Дәүләт Советына әлеге тәкъдимне Дәүләт Думасына җиткерергә киңәш итте.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Өстенлек – тизлек һәм сыйфатка

Татарстанда узган ел кеше үтерүгә бәйле җинаятьләр саны 20 процентка кимегән. Аның каравы күпчелеге шәхескә карата булган. Еллар буе чишелмичә калган эшләрне дә ерак тартмага салмаганнар.

Россия Тикшерү комитетының Татарстан буенча идарәсе коллегиясендә узган елга йомгак ясадылар.

Барлык хокук саклау органнарының бердәм эшләве җинаятьчеләрне фаш итүдә яхшы нәтиҗәләр биргән. Идарә башлыгы вазыйфаларын башкаручы Марсель Дулкарнаев әйтүенчә, республикада кырын эшләрнең 4 процентка кимүе – моның дәлиле.

– 2021 елда Татарстанда узган еллардагы 110 җинаять ачылган һәм тикшерелгән. Моннан тыш, идарә хезмәткәрләре 54 авыр һәм аеруча авыр җинаятьләрне ачыклый алды, – дип хисап тотты ул.

Саннарның тагын да саллылары ачылган җинаять эшләрендә чагыла. Тикшерүчеләр 4 939 җинаять эше кузгаткан, 2 343е судка тапшырылган. Узган елда кылынган җинаятьләрдән зыян күрүчеләргә һәм дәүләткә 1 млрд 400 млн сум акча кире кайтарылган, гаепләнүчеләр милкенә 1,2 млрд сумлык арест салынган.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов идарәнең эшчәнлеге турында хисапны тыңлаганнан соң, тикшерү хезмәткәрләре алдында җаваплы бурычлар торганын искәртте.

– Тизлек һәм сыйфат – сезнең эштә өстенлек менә шуларга бирелә, – диде ул. – Иң мөһим бурычларның берсе – икътисади җинаятьләргә каршы көрәш, салым салу, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне саклау өлкәсенә дә игътибар итү. Бизнеска басым ясау, дин һәм миллитара низагларны булдырмау да әһәмиятле.

ЯЗГА КЕРЕП БАРЫШ

ТР Дәүләт Советында

Кичә парламентыбыз язгы сессиянең беренче утырышын үткәрде. Безне иң беренче чиратта җирле үзидарә турында федераль закон язмышы кызыксындырды. Ул Думада беренче укылышта кабул ителде.

Без 23 февральгә хәтле үз сүзебезне әйтергә тиеш. Исегезгә төшерик, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» дип аталган федераль закон проектына төзәтмәләр тәкъдим итәр өчен бездә эшче төркем дә төзелгән иде. Әлеге проект муниципаль район һәм шәһәр округлары башлыкларына да җибәрелде, сәяси партияләрнең фикерләре дә исәпкә алынды һәм бер сүзгә килende. Сессия утырышында Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе Альберт Хәбибуллин Татарстан тәкъдим итәсе 13 төзәтмәнең кайберләре белән таныштырды. Шунысын да әйтик әле: Федераль закон гамәлгә кергән очракта, республикадагы 956 муниципаль берәмлек (болар – ике шәһәр округы, 43 муниципаль район, 39 шәһәр һәм 872 авыл җирлекләре) 911гә калырга тиеш була.

Альберт Хәбибуллин әйтүенчә, безнең төп тәкъдимнәребез берсе муниципаль берәмлек башлыкларын сайлап куюның гамәлдәге схемасын саклап калу турында. Ягъни муниципаль депутатлар арасыннан сайланган кеше җирле хакимиятне җитәкли башлагач кына депутат вәкаләтләреннән азат ителергә тиеш. Ә яңа закон проекты бу принципны үзгәртә. Җитәкченең депутат вәкаләтләреннән азат ителүе аның җирле җитәкче вазыйфаларын башкару-башкармавына бәйле булмаячак. Бу исә җирле депутатлар каршында аның абруен төшерәчәк. Ә моңа хәтле эшләп килгән модель үзен тормышта раслаган иде.

Тагын бер төзәтмә җирле үзидарәнең бер баскычлы модельгә күчүенә бәйле. Ягъни Татарстанга авыл җирлеге депутатлары кирәкми. Президент Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә дә, ике баскычлы җирле үзидарә системасы бер илдә дә юк. Шул ук вакытта ул җирле хакимият белән халык арасында элемтә бозылмаячагын, бөтен структуралар сакланачагын, аларга бары тик муниципаль округ вәкаләтләре биреләчәген белдерә. Әйткәнебезчә, республикада 956 муниципаль берәмлек һәм 7 мең «муниципаль депутат» булуны хупламый иде президент. Аның әйтүенчә, шәһәр һәм муниципаль округлар оешып, аларның вәкилләре урыннарда эшли алалар һәм бүгенге заманда мондый система нәтиҗәле булыр иде.

Җирле үзидарә системасына кагылышлы үзгәрешләр турында кайта-кайта язарга туры киләчәк әле. Төзәтмәләрне Дума аша үткәрү кебек мактаулы бурыч Татарстаннан сайланган депутат Айрат Фәррахов йөкләнде.

«Хөкүмәт сәгате» республикада Дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен тормышка ашыруга багышланган иде. Яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов әйтүенчә, Татарстанда яшьләр сәясәте моннан 29 ел элек үткәрелә башлаган һәм зур тәҗрибә тупланган, әмма заман яңадан-яңа таләпләр куя тора. Беренчедән, министрны демографик факторлар борчый иде. 2030 елга 25–35 яшьтәгеләр санының 250 меңгә кимүе көтелә. Бу яшьтәгеләр исә – һәр өлкәдә төп көч.

Яшьләрне эшкә урнаштыру да киечектергесез хәл итүне сорый. Бүген икътисад тармагында яшьләрнең өлеше нибары 13,6%. Моннан 4 ел элек кенә 16,1% булган. «Яшьләр дәүләтнең кайгыртучанлыгын, ярдәмен тоеп яшәргә тиеш», – ди Тимур Сөләйманов. Әлбәттә, министр чыгышы зарлануга корылмаган иде. Киресенчә, килеп туган һәр проблеманы чишү юлларын күрсәтеп сөйләде ул. Яшьләр сәясәтен тормышка ашырыр өчен республика бюджетыннан узган ел гына да 6 млрд сум акча бирелгән. Ул акчаның шактые төрле районнарда яшьләр үзәкләре төзү йә ремонтлауга, үсмерләр клублары ачуга китә. Әлеге үзәкләр һәм клубларның яшьләрне тәрбияләүдә зур эш башкаруы бәхәссез. Чөнки урам һәм интернет тәрбиясенең тискәре йогынтысын һәрберебез күреп-белеп тора. Бездә «проблемалы» яшьләр 2400 икән. Психология үзәкләренә мөрәҗәгать итүчеләр 100 меңнән арткан. Кыскасы, Яшьләр эшләре министрлыгының мәшәкатьләре хәттин ашкан. Парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин яшьләр сәясәте буенча стратегик программаларны закон дәрәҗәсенә күтәрергә кирәк дип саный. Хәзергә министрлык эше уңай бәяләнде.

Сессия утырышында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә кагылышлы законга үзгәреш кертү турында закон проекты каралган иде. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова әйтүенчә, аз керемле саналган 1534 кешегә узган ел социаль түләүләр эләкмәгән. Сәбәбе бик гади, аларның мал-мөлкәтен санаганда җыен каралты-кура да исәпкә алынган булган. Законга тәкъдим ителгән төзәтмә буенча, мәйданы 15 кв. метрдан артмаган хуҗалык корылмалары милеккә саналмаячак. Димәк, социаль түләүдән мәхрүм калган әлеге гражданнарга кечкенә булса да бәхет елмаер. Депутатлар: «Ни өчен унбиш, мәсәлән, унсигез квадрат метр түгел?» – дип шаулаша башлаганнар иде, парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин: «Закон проектын шул килеш кабул итә торыйк, өстәргә беркайчан да соң булмас», – дип, халыкны тынычландырды.

Узбезнең законнарны федераль кысага кертүгә бәйле закон проектлары исә берьюлы каралды. Бүтән бәхәсле мәсьәләләр дә килеп чыкмады. Ә күңел нигәдер язгы кыбырсыну көткән иде. Хәер, яз башланырга гына тора бит әле.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Айдар ШӘЙХИН

ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

ФӘЛСӘФӘ ФӘЙЛӘСҮФ ФИЛОСОФИЯ

Гыйнварның соңгы көнендә игътибарлы татар җәмәгатьчелеге милләттәшләребез арасында беренче фәлсәфә фәннәре докторы Мансур Абдрахмановның тууына 110 ел тулуны искә алды. Мансур Абдрахманов татар телендә фәлсәфи хезмәтләр, шул исәптән, «Диалектик материализм» дәреслеген язган.

Философия – телнең функциональ егәрлеген, гади итеп әйткәндә, көчен күрсәтә торган иң ышанычлы корал. Бу уңайдан тел дәресләребездә янәдән фәлсәфә сүзләренә тукталып алырга рөхсәт итегез. Озакка түгел: бер төшенчәне генә аңлатып китик.

Бу фәннең (әгәр дә аны фән дип атарга яраса инде) атамасы татарча ничек була соң? *Философиямы, фәлсәфәме?* Бу сорауны буш мәсьәлә дип кабул итә күрмәгез. Эш шунда ки, гарәп-мөселман фәлсәфи фикеренең бер этабы хәзерге рус телендәге хезмәтләрдә *фальсафа* дип атала. Башлыча Аристотель һәм Платон традицияләреннән үсеп чыгып, грек-латин философиясенә нигезләнгәнгә күрә, ул дәвердә яшәгән хикмәт ияләренең уй сөреше философия – фәлсәфә дип әйтелә. Ә шул ук гарәп-мөселман философиясенең башка этаплары һәм юнәлешләренә карата бу термин кулланылмый. Димәк, татарчага тәрҗемә иткәндә, төшенчәләрдә каршылык килеп чыга.

Әлбәттә, бу газета укучылары көндәлек тормышта килеп абына торган очраклар түгел. Әмма телебезнең мантыйгын, тәрҗемә эшләрендә саклык һәм игътибарлылыкның әһәмиятен аңлар өчен, мондый очракларны да өйрәнергә кирәк.

Төрки-татар язма традициясенә философик категорияләр һәм төшенчәләр гарәп-мөселман мәдәнияте һәм философиясе аша үтеп керә. Шунлыктан, хәзерге әдәби телебездә рәхәтләнеп «фәлсәфә» төшенчәсен кулланырга кирәк. Философия сүзенең дә бер зыяны юк: бу – халыкара төшенчә, башка телләрдәге сүзләргә нигез булып тора.

Фәлсәфә белән шөгыльләнүчеләрне исә кайвакыт *фәйләсүфләр/фәйләсуфләр* дип атыйлар. Бу – гарәпчәдән туры алынган вариант. Кайбер әдәби текстларда аны куллану урынлы булырга мөмкин. Гомумән алганда, «философ» һәм «фәлсәфәче» сүзләрен куллану хәерлерәк.

КАЙБЕР ХАТАЛАРГА КҮЗӘТҮ

◆*Кем генә булмасак та* (Кем бы мы ни были). Рус теленнән сүзгә-сүз тәрҗемә итәргә тырышып, *ни* кисәкчәсен татарчага *булу* фигыленең юклык формасы аша белдерү нәтиҗәсе. Дөрес варианты: *кем генә булсак та.*

◆*Кайчан мин мәктәпкә бардым.* Мондый җөмләләр көндәлек аралашуда да, социаль челтәрләрдәге сәхифәләрдә дә, кайбер басма текстларда да көннән-көн ныграк очрый. Бу – телебез кичерә торган куркыныч үзгәрешләрнең бер чагылышы. «Чыктым аркылы күпер» дигән гыйбарә нәкъ менә шушындый җөмләләр турында бит инде. Әгәр дә шикләнәсез икән, беркайчан да *кайчан* алмашлыгын җөмләнең башына куймагыз. Әлбәттә, ул җөмлә башында да килә ала (ике җөмләдәге мәгънәләрне бер-берсенә капма-каршы куеп әйткәндә һәр җөмлә алдыннан китерелә, «нинди вакытта гына булмасын, һәрвакыт» мәгънәсендә килгәндә җөмлә башында була ала, *кайчан карама, кайчан да булса* кебек тезмәләрнең башында була). Ләкин югарыда китерелгән мисалда, аңлашыла ки, русчадан тәрҗемә итү хатасы күзәтелә. Дөресе: *Мин мәктәпкә баргач, мин мәктәпкә барганда.*

Әйтеп кенә бактым

Илнар
ХӨСНУЛЛИН

Зәйнәп ник елый?

Безне ник яратмыйлар? Ни өчен безнекеләргә генә каныгалар? Спорт сөючеләрне тизлек, җитезлек, осталык белән гаҗәпләндерергә тиешле Пекин Олимпиадасыннан күңелсез хәбәрләр килеп ирешкәч, әнә шул сорауларга җавап таба алмый изаланучылар күп булды бу көннәрдә.

Чәршәмбенең буранлы кичендә балалар бүлмәсеннән 14 яшен тутыручы кызыбыз Зәйнәпнең үксеп-үксеп елаган тавышын ишеткәч, әнисе белән бүлмәгә атылып кердек. Әллә «бишле» артыннан куып, төнге сәгать 10га кадәр өй эше белән чиләнеп утыруны гадәт иткән кызның укуында берәр нәрсә килеп чыкканмы? Юк икән. Күз яше агызуның сәбәбе гадирәк. Спорт турында язучы бер басманың журналистлары халык игътибарын җәлеп итү өчен тараткан ялган хәбәр моның телефонына да килеп ирешкән. «Ник ул Камиләне беркем дә якламый соң?» – диде кызыбыз. Башка вакытта сорауларга һич югы хәйлә юлы белән ничек тә җавап бирергә тырышсак, бу юлы килеп чыкмады.

Пекин Олимпиадасының фигуралы шуу буенча команда ярышларында җиңгән Россия спортчыларына алтын медальләрнең вакытында тапшырылмауның сәбәбе чәршәмбе иртәсендә ачыкланды. Беләбез бит инде: төгәл мәгълүмат булмагач, имеш-мимешләр арта гына бара. Шулай итеп, безнең спортчыда допинг табулары, ә соңрак ул кешенең Камилә Вәлиева булуы турында хәбәрләр тиз таралды. Үзен абруйлы дип санаган бер басма 15 яшьлек кызчыкның шәхси ярышларга кертелмәячәген, команданың исә алтынсыз калачагын җиткерде. Хәер, соңрак үз сүзләрен кире алдылар, әмма спорт сөючеләр дә, сөймәүчеләр дә телефонга кереп киткән иде инде.

Дөресен әйткәндә, тыелган матдәнең башка спортчыда табылуы турында хәбәр чыкса, бу кадәр игътибар итүче дә булмас иде. Нишләмәк кирәк, иялләшеп киттек без мондый вакыйгаларга. Безне яратмыйлар инде, чөнки көнләшәләр, шуңа каныгалар, дип үзебезне күпме генә акларга тырышсак та, допинг куллану очраклары барлыгын кире кагып булмый. Ул тырмага аз басмадык соңгы елларда. Махсус хезмәтләр саклап-күзәтеп торган килеш, миллиардлаган сумлык проектлар пыран-заран китерелгәндә, җиңү өчен барысына да әзер булган спортчыга дару каптыруның нәрсәсе бар инде?

Әлбәттә, 15 яшендә кызчыкның, үзе белеп, тыелган матдә куллануын берничек тә күз алдына китереп булмый. Бу юллар язылганда әлеге вакыйга буенча рәсми мәгълүмат юк иде. Билгесез чыганакларга таянып җиткерелгәннәренә ышансаң, команда беренчелегендә яуланган алтын медальгә кагылмыйлар, ә Камиләгә шәхси ярышта чыгыш ясарга рөхсәт бирәләр. Әмма шау-шу тиз генә тынмаячак әле. Безне яратмаган өчен көнләшкән, шуңа күрә каныккан көндәшләр бу мәсьәләгә кабат әйләнеп кайтачак. Безнекеләр дә онытмасын иде бу вакыйганы. Спорт түрәләре Россиянең быелгы Олимпиадада, һич арттырусыз, төп өметенә әверелгән баланы җил-яңгырыннан да, шиктән дә, башкасыннан да сакларга һәм якларга тиеш иде. Ярыштан соң медаль белән мактану һәм җитәкчелек алдында эш күрсәтү генә түгел, ә киләчәк өчен. Чөнки Зәйнәпне һәм башкаларны ватанпәрвәрлек турындагы матур сүзләр белән юатып булмый. Аларга өмет кирәк. Өметне исә Камиләләр өләшә.

Йөгәнсез һәм авызлыксыз бәяләр

Россия хөкүмәтенең, ил җитәкчелегенең һәм Үзәк банкның бәяләрне йөгәнләргә омтылышы кире пропорциональ нәтиҗәләргә китерә, ягъни көрәш көчәйгән саен, бәяләр ныграк үсә. Икътисади үсеш министрлыгы үткән ел бәяләрнең түшәмгә килеп терәлүе турында биш тапкыр игълан иткән, бишесендә дә инфляция угы түшәмне тишеп чыккан. 2022 елда бәяләр үсеше туктаулыр дигән өметләр бер дә акланырга охшамаган, чөнки гыйнвар инфляциясе үк инде, еллыкка күчереп исәпләгәч, 9 процентка якынлаша.

Киң куллану товарлары инфляциясе, рәсми инфляцияне кимендә ике тапкыр узып, алга омтыла. «Ромир» 1,5 миллион россиялeнең гыйнвар аенда сатып алган товарларын анализлаган да аларның бәясе үткән елның гыйнварына караганда 18 процентка югарырак булуын ачыклаган. Шулай булгач, рәсми инфляциянең кечерәк булуыннан безнең кесәләр калынаймый, әлбәттә. Кремльдә дә инде инфляция безне бил алышканда, түрәләр түгел, бәяләр күтәрелеше җиңүен таныйлар. Президент сүзчесе Песков әфәнде: «Инфляция басымы дәвам итә, һәм ул басымның кайчан тәгәлләнәсен әлегә әйтү кыен», – дип белдерде. Кыен булса да, без әйтеп бирәбез: басым, ягъни бәяләр күтәрелеше тәмамланмаячак. Фаразга бераз төгәллек кертик: хәзерге икътисад сәясәте дәвам иткәндә, бәяләр чүпрәсе туктаусыз кабарачак. Икътисад сәясәтен алыштырырга җыенган кешеләр күренми әле.

Әйе, әйе, чиновниклар бәяләргә авызлык кидертергә тырышмыйлар түгел, тырышалар. Фәкыйрьләр ризыгы белән сәүдә оештыручы ритейлерларга басым ясыйлар, сату бәясенә өстәлә торган процентларны кисәләр, прокуратура кибетләрне тикшереп карый… Нәтиҗәсен күрәбез бит инде: бәяләр барыбер үсүдән туктамый.

Инфляция басымы урынына административ басым ясый башласаң, бизнес нишли? Аягын суза. Яисә җитештерүне бик нык киметеп, исән калырга тырышып карый. Җитештерүне киметсәң, дефицит барлыкка килә. Бәяләр үсеше фонында товар кытлыгы – хәзерге глобаль капитализмның бер могҗизасы бит инде ул. Андый хәл социализмда да булмаган иде. Арзанлы товар кытлыгы гына күзәтелде. Базарда кыйммәт бәядән товар табып алу хәтта СССРның соңгы елларында да мөмкин эш иде. Хәзер товар кыйммәт, әмма барыбер кайбер нәрсәләрне таба алмыйсың. Авылда Кытай тракторы бар иде. Үткән елның сентябрендә тапшырулар тартмасы (коробка передач) ватылып эштән чыкты. Кичә генә тракторчысыннан сорадым, Кытайдан коробка килеп җитмәү сәбәпле ремонтланмый тора икән техника.

Акчага товар табып булмау һәм бәяләрнең котырып үсүе ул – системаның үлем чире белән чирләвен күрсәтә торган билге. Ковид белән авыручылар нидән үләләр әле гадәттә? Кислород җитмәүдән. Һавада кислород бар ул, эштән чыккан үпкәләр аны үзләштерә алмый, бары шул гына. Глобаль капитализмның да «үпкә»се җәмгыятьнең ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый башлады. Хәзер таралган чирнең тагын бер үзенчәлеге бар бит: үпкәләрне вирус түгел, иммунитет күзәнәкләре эштән чыгара, сулыш органнын сакларга дип яратылган сакчылар, һөҗүм итеп, аны үтерә. Шуңа күрә дәвалау протоколларына табиблар авыр хәлдәге пациентларның иммунитетын баса торган дарулар өсти. Медицина терминнары белән яза башлавым өчен гафу үтенәм, әмма хәзерге «пандемия кризисы» дип аталган кризис та авыру үпкәсенә охшаган. Икътисадның иммун күзәнәге дә, кислороды да – акча бит аның. Акчаның җитмәве икътисадның тынын кыса, артыклыгы аны үтерә. Барлык империяләрнең дә һәлакәте шуңа бәйләнгән. СССРның түнтәрелеше акча күплектән булды. Бу – иң соңгы мисал гына.

Еракрак китеп, тагын бер-ике мисал китерәм. Беләсезме, дөнья тарихындагы иң бай кеше – Илон Маск та, Цукерберг та түгел, ә XIV гасырда ук яшәгән Африкадагы Мали империясен идарә иткән Муса Кейт I дигән патша. 1312 елда идарәгә килгән ул патшаның алтын акчалары шулкадәр күп була: хәзерге долларга әверелдергәч, Маск белән Цукерберг Муса янында фәкыйрьләр булып тоелыр иде. Хәзерге миллиардерларның байлыгы чын байлык түгел, куык кына икәнен искә алганда бу бигрәк тә шулай. Әнә үткән атнада гына Цукерберг байлыгы «пышш» итеп кенә шиңде дә (биржада акцияләре очсызланды чөнки), ул дөньядагы иң бай кешеләр исемлегеннән сызылды. Мали патшасының исә алтыннары алай шиңеп юкка чыга торган түгел. Ул чакта, XIV гасырда европалылар ач һәм ялангач вакытта, Малида чып-чын цивилизация чәчәк ата, муллык ташый, тормыш кайный. Хәзер дә бик бай ул ил, европалыларның гаскәрләре шуңа күрә аны ташлап китмәс өчен җан тартышып ята, курчак хөкүмәтләр оештырып имәләр генә аның байлыгын!

Менә шул Муса 1324 елда хаҗга бара. Искәртик: Малида хәзер дә мөселманнар яши, европалылар үз гаскәрләрен анда тотуларының сәбәбен илне талау дип түгел, ислам терроруна каршы көрәшү дип игълан итәләр. Муса хаҗга дистә меңләгән солдат, хезмәтче белән йөзләгән һәм меңләгән ат-дөягә алтын акча төяп бара. Юлында ул фәкыйрьләргә санап тормыйча күпләп алтын өләшә һәм шуның белән юл өстендәге Мисыр дәүләтен җимереп ташлый яза. Мисырда коточкыч инфляция башлана, Мали патшасына, кире кайтканда, үзе өләшкән алтыннарны кире сатып алырга да туры килә хәтта. Шуңа карамастан, Каһирәгә инфляцион кризистан котылу өчен еллар кирәк була әле.

Алтын акчаның күплеге тагын бер дәүләтне державалар исемлегеннән сызып ташлый. Колумб Американы ачкач, андагы җирле халыкларның алтынын талап, Испаниягә ташу башлана. Ул чорның куәтле державасы булган Испания алтын күплектән сыгылып килә. Иң беренче авыл хуҗалыгы бөлә, чөнки азык-төлекне күпләп чит илдән сатып алу башлана. Алтын күп бит.

Бу ике мисал хәзерге икътисад кризисының асылын аңлата да бирә инде безгә. Хәзер акчаны алтыннан коймыйлар, кәгазьгә генә басалар. Доллар күплеге, евро күплеге, фунт күплеге, рубль күплеге китерә инфляциягә. «Инфляция» дигән сүз бит ул акча-товар чагыштырмасын аңлата. Акча товарга караганда күбрәк икән, бәяләр үсә, товар күбәйсә, бәяләр төшә. Типография станоклары бертуктаусыз эшләгәнгә күрә, акча һәрвакытта да товарга караганда күбрәк була. Менә шуңа күрә Үзәк банк ставканы күпме генә күтәрмәсен, бәяләр төшми барыбер. Кешеләр реаль инфляциянең рәсми бәяләр күтәрелешеннән ике-өч тапкыр күбрәк икәнен күреп тора, шуңа күрә өстенлекне товар җыеп калуга бирә. Кредит алалар да йорт салалар, машина алыштыралар. Бәяләр тагын да үсә инде шулай булгач. АКШта әнә доллар станогын акрынайтмакчы булалар. Шулай эшләмәсәләр, доллар бервакыт бәдрәф кәгазеннән арзанрак йөри башларга мөмкин. Бу инде болай да калтырап торган империянең җимерелүен аңлатачак. Әмма долларны тотып торырга россиялеләр һәм башка ил халыклары да булыша. Үз акчаларына Америка кәгазен сатып алалар. Акчага акча сатып алу – гаҗәп нәрсә инде ул, әмма долларга берникадәр ныклык өсти. Янкиларны безгә караганда муллрак тормышта яшәтә. Россия фәкыйрьләре Америка миллиардерларына сәдака бирәләр дип аңлатып булыр иде моны. Вәләкин куыклар шулкадәр кабарган: хәзер аларны тотып тору өчен хәерчеләр акчасы гына җитми. Фронт сызыгына гаскәрләрне тезәргә туры килә. Янкилар монда да отмакчы була, ике тугандаш халыкны сугыштырып, каймагын үзләре җыеп алырга телиләр. Бу әлегә барып чыга кебек. Менә кайларга алып чыга безне чамасыз акча басу сәясәте.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

КӨТЕЛМӘГӘН БҮЛӘК

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Үз кеше

– Бездән еш кына, ни өчен абунәчеләрегез арасында һаман бүләк уйнатасыз, дип сорыйлар. Беренчедән, аны укучыларыбыз көтә. Язылучылар арасында нинди бүләк уйнатканны әйтеп өлгергәнче үк, язылу турында квитанцияләрен редакциягә җибәрә башлыйлар. Икенчедән, укучыларыбызны сөендерү үзебезгә дә бик ошый. Бүләк откан кешедән ким сөенмибез. Авылдашыгыз Фаварис абый Галиев өчен дә бөтен коллективыбыз белән куандык. Фаварис абый, игелекле бүләк булсын! – диде баш мөхәррир урынбасары Зөлфия Хәлиуллина Смәел авылында мини-тракторны тапшырганда.

Фаварис абый Галиев «Ватаным Татарстан» өчен үз кеше булып чыкты.

– 70 ел укыйм инде мин газетаны. Гаиләбез белән гомер буе яздырып укыдык, – диде ул. Шушы сүзләрне ишеткәч, аның шатлыгын уртаклашырга килгән авылдашлары да «ууу» дип гөжләп алды. – Өстәвенә 1934 нче елларда, алдынгы эшче дип, әтиемнең фотосы басылган; студент чакта, үземне дә мактап, фотомны чыгардылар. Шигырьләрем дә күп тапкыр дөнья күрде. Бүләгегез өчен зур рәхмәт, котлап шалтыратмаган кеше калмады да бугай, бөтен авыл өчен зур вакыйга булды ул. Исәнсау эшләгез, газетагыз бик эчтәлекле, укылышлы. Бөтен темаларны да яктыртасыз, кешеләрне борчыган сорауларга җаваплар бирәсез. Алга таба да иҗат чишмәгез саекмасын, укучыларыгыз күп булсын.

Фаварис абый – райондашларына билгеле шәхес. Шигырьләр, җырлар яза, 40 яшьтән соң гына иҗат итә башласа да, ике китап авторы. 2016 елдан авыл тарихын язу белән мәшгуль. Туган авылы Смәелдә кырык елдан артык агроном, партоешма секретаре, колхоз рәисе урынбасары булып эшләп, хөрмәт яулаган кеше, Россиянең атказанган агрономы (районда бу мактаулы исемгә лаек булган ике кешенең берсе). Тормыш иптәше, шулай ук үз эшенең остасы булып танылган, балаларга күп еллар белем биргән Гөлсем ханым белән 53 ел тату гомер кичереп, үткән ел «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медале белән бүләкләнгәннәр. 2021 елда Фаварис абыйга 80 яшь тулса, быел Гөлсем апаның юбилее булачак икән. Мини-трактор менә шушы барлык бәйрәмнәргә көтелмәгән бүләк булган.

– Их, моннан ун-унбиш ел элек булмады мондый трактор, нишләргә белер идем, – дип шаярткан Фаварис абыйга «Смәел» хуҗалыгы җитәкчесе Илһам Шакиров кушылды: «Язгы кыр эшләренә менә тагын бер техника булды, тракторчысы да әзер». Авылдашлары арасында да язын бакча эшкәртергә дип инде «чиратка язылучылар» да шактый иде. Җирле үзидарә башлыгы Рифнур Йосыпов, ветераннар советы рәисе Солтан Фатыйхов та, бүләкнең бик лаеклы булуын әйтеп, иясенә изге теләкләрен җиткерделәр. Чарага килүчеләр арасында бүләк трактор белән чын-чыннан кызыксынучылар да табылды. Кызыгырлык та шул. Авылда мондый техника ел әйләнәсе артык булмый лабаса. Әнә бит, быел кар күп яуганны сылтау итеп: «Иң элек кар эттергеч җайланма куярга кирәк, вәт шәп булачак!» – диюче дә табылды.

Һөнәрчеләр төбәге

Смәел гомер-гомергә Балтач районында иң һөнәрле авылларның берсе булды. Бигрәк тә тал чыбыгыннан урындык, бишек, өстәл, бәби арбалары һәм башка йорт кирәк-яраклары ясаучылары белән дан тота ул. Бу һөнәрнең чын остасы Хәмәтнәби Шәяхмәтов исемле кеше була. Заманында бөтен Россиягә танылган шушы районның Чепья авылындагы үргән әйберләр фабрикасы осталары да бу эшкә аңардан өйрәнгән булып чыкты. Аның эшен бертуган Харис, Васил Якуповлар дәвам иттергән. Харисның улы Рәис әле бүген дә заказлар буенча тал чыбыгыннан әйберләр үрә, диделәр. Авыл заманында һәвәскәр скульптор Габдулла Гыйззәтуллин белән күп мактаулы, Советлар Союзы Герое булган авылдашлары Гайфетдин Гыйльметдинов белән горурланды, бу авылның балта осталарының даны да еракларга таралган иде.

Хәер, авыл бүген дә эшле, ашлы, һөнәрле. Чәчәкләр үстерүче Илнур Латыйпов турында берничә тапкыр яздык инде. Бу тырыш егетнең планнары зурдан, быел теплицаларын тагын да киңәйтә, диделәр.

Үзләре яшьләр кайтмый, авыл картая дияргә яратса да, читтән килгән кеше биредәге берсеннән-берсе таза, заманча йорт-каралтыларга карап тел шартлатырлык әле.

– Авылда бүген 754 кеше яши, шуларның 156сы – 18 яшькә кадәргеләр. Мәктәптә 114 укучы белем ала, 26 бала бакчага йөри, – дип таныштыра авыл җирлеге секретаре Гөлзидә Зәкиуллина. – Узган ел алты өлкән кешебезгә 90–95 яшь тулды, 80–85 яшьлекләр – ун кеше.

Баксаң, киткән яшьләрнең дә күпчелеге әле авылдан бөтенләй тамырларын өзмәгән: кайта-китә йөриләр, шунлыктан, анда җиргә сеңеп беткән, караучысыз калган йорт юк икән.

Авыл халкы куплап терлек асрый. Иң сөенгәннәре: төп нигездә калып, өлкәннәр белән бергә яшәүче гаиләләр бу яктан барысына да үрнәк күрсәтә икән. Авылның дәвамчылары булган шундый дүрт хуҗалыкта сигез-тугызар сыер асралса, берәр хуҗалыкта – унбер һәм унбиш, ә ике хуҗалыкта унөчәр сыер асрыйлар. Радик Нәбиев хуҗалыгында исә сыерлар саны 20гә җиткән. Үткән ел дәүләткә иң күп сөтне дә Нәбиевләр тапшырган: 59185 литр! Фаил Мөхәммәдиев, Расил Гыйлаҗетдинов хуҗалыклары да, алардан азга гына калышып, 44096 һәм 39427 литр сөт сатканнар. Хезмәте-мәшәкате күп булса да, зарланмыйча эшләп яшәргә күнеккән кешегә, ни дисәң дә, сөбханалла дип әйтерлек өстәмә. Сыер малыннан тыш Смәелдә 32 баш кәҗә, 26 баш ат та асрыйлар әле.

– Авылда төп эш урыны, төп акча кереме барыбер, элеккечә әйтсәк, колхоздан инде, – ди Фаварис абый, авылның бүгенгесе белән таныштыруны дәвам итеп. – Шөкер, җитәкчебездән бик уңдык. Илһам – үзебезнең авыл егете. Бик тырыш, тәвәккәл егет. Печән-салам, ашлык белән дә тәэмин итә, авылдагы бөтен проблемаларны да аңа әйтәбез, гозер белән барсаң да, кире бормый... Бөтен нәрсә дә кеше факторыннан тора бит. Менә безнең авылда гомергә көрәшчеләр булмады. Күрше авыл егете Альберт Миңнеханов авыл яшьләре белән шөгыльләнә башлаган иде, узган ел ахырында район башлыгы призына үткәрелгән ярышта безнең команда дүртенче урынны алды. Авыл өчен күрелмәгән хәл бу. Билгеле, тренер үзе генә берни дә эшли алмый, бу егетләрне үсендереп-ярдәм итеп торучы Илһам кебек җитәкче дә кирәк.

«Смәел» хуҗалыгы – районда сөтчелек тармагында зур борылыш ясаган хуҗалык дисәң дә арттыру булмас. Беренчеләрдән булып, мегаферма төзергә алынган әлеге хуҗалык җитәкчесе турында башкаладан килгән дәрәҗәле кунаклардан да «ике йөрәкле егеттер бу» дигәнне ишетергә туры килде. Аның үрнәгендә инде карусельле фермалар хәзер Балтачта табигый хәлгә әйләнде. Районныкылар гына түгел, читләр дә килеп өйрәнде. «Белгечләребез бар да үзебезнеке, проблема юк. Машина-трактор парклары да яңартылып тора, авылда эшлим, яшим дигән кешегә шартлар да бар, мөмкинлектән чыгып, ярдәм итәргә дә тырышабыз», – ди Илһам.

Авыл халкы 958850 сумлык газета-журналларга язылган. Айга 1986 данә газета, 115 журнал килә, диләр. Авыл кешесе самими бит ул, эчендәгесе – тышында дигәндәй, бу чарада катнашучылар арасында: «Әле моңарчы сезнең газетага язылмаган идем, болай булгач, язылмый калып булмас», – диюче дә булды.

Бар да бар, тик...

Мини-трактор тапшыру тантанасы 2020 елгы капиталь ремонттан соң танымаслык булып үзгәргән мәдәният йорты каршында үтте. Янәшәдә генә – үткән ел ишекләрен ачкан өр-яңа ФАП, бераз читтәрәк – федераль программа буенча үткән ел төзелгән хоккей мәйданчыгы. Мәктәп белән балалар бакчасына да берничә ел элек ремонт кергән, алар да төзек, авылда биш кибет бар икән. «Үзара салым программасы буенча соңгы елларда күп эшләнде, – ди авыл җирлеге башлыгы Рифнур Йосыпов. – Авыл эчендәге юллар, чишмә-коелар, янгын куркынычсызлыгы гидрантлары, зират коймалары тәртипкә китерелде, уен мәйданчыгы төзелде». Смәеллеләрне бары бер әйбер борчый булып чыкты: олы юлдан авылга килүче юл начарланган. Югыйсә ерак ара да түгел. Кайчандыр асфальт салынган юллары төп проблемага әйләнгән. Проектлары да эшләнгән икән инде. Озак көтәргә туры килмәс дип ышаныйк.

– Авыл тарихын язарга алынуымның файда-табышлары бик күп булды, – ди героебыз Фаварис абый. – Ундүрт буынга кадәр нәселебезне белдем. Мин төзегән китап буенча күпчелек авылдашлар да беләчәк. Без – ундүрт буын шушы авылда яшәгән нәсел. Әмма, болай дәвам итсә, бездән соң авылда нәсел киселәчәк. Дөрес, бер улым авылда калды, эшеме дәвам иттерә, хуҗалыкта баш агроном, янәшәбезгә йорт җиткереп, башка чыкты. Аның улы – оныгыбыз – авылга кайтам дими ләкин. Менә шуңа эчем бик поша. Җәмәгатем Гөлсем белән без һәр кичне авыл урамын әйләнәбез. Менә шунда кемнең дәвамчылары кайда икәнен карап, уйланып йөрибез...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ДӘВАСЫЗ «ЧИР»

Балыкчыны су буена балык кына тартамы? Кышкы балык тотуның ни рәхәте бар? Бу – чыгымлы мавыгумы? Балыкчылар фәлсәфәсенә төшенергә тырыштык.

Илдар Мөхәммәтҗанов / Марат Хәбибуллин

Кышын кызыграк

Кышын балык тотуны сәнгатькә тиңли һәвәскәр балыкчылар. Сүзләрендә хаклык бардыр да: чатнама суык та, үтәли җиле дә, боз өстендә утыру да куркытмый бит аларны. Түземлекләренә дә ис китәрлек. Аларны җәлләмәгән кешеләр дә сирәктер. «Кибеттән дә алып була бит ул балыкны, нужа йөртәме инде?» – дип борчылганнар да юк түгел.

Байлар Сабасыннан Хәниф Тимербаев, тәпи киткәннән бирле балыкка йөрим, ди. Үзе мәдәният бүлегендә эшли. Атнасына бер тапкыр булса да, суга төшеп, кармак салып керә ул.

– Мишә буенда үскән егет бит мин. Әтигә ияреп йөрелгән башта. Аннан үзем генә йөри башладым. Әни кычыткан тотып эзләргә чыга иде, кеше-фәлән күрмәгәндә, тагын чыгып кача идем. Җәен безнең бар шөгыль – эш һәм балык тоту булды, – дип сөйләде ул. – Урысларда шундый сүз бар: «Не за рыбой, а на рыбалку». Без дә шул. Тотсак – шәп, тотмасак та начар түгел. Физик хәрәкәт бит ул. Бер баруда 15 чакрым җәяү йөрисең, әллә ничә тишем тишәсең. Җанга рәхәтлек бирә ул бер барып кайту. Адреналин аласың. Быел балык әйбәт эләкте. Су аз, балыкның качар җире юк. Мактанып әйтүем түгел, әмма бозга кергәндә курыккан юк. Һәр кешенең берәр шөгыле булырга тиеш. Болай да диванда күп ятабыз. Балык тотарга барып, гәүдәне яздырып кайтсаң, ничек әйбәт бит!

Һәвәскәр балыкчы гына түгел, 1999 елдан бирле Сабада җәйге-кышкы балык тоту ярышларын оештыручы да әле ул. Йөзәрләгән балыкчы катнаша икән. «Иң күп балыкчылар – Сабададыр», – ди.

Балык тотуны кәсепкә әйләндерү өчен тырышмый Хәниф абый. Шулай да быел 2 мең сумлык балык саткан. Гадәттә тоткан кадәрен гел өләшә икән. «Күчтәнәч итеп бирү рәхәтрәк бит. Балык тоткан кешеләрнең күбесе үз уңышын ашамый», – ди үзе дә.

Үзен ялгызак балыкчы дип саный икән Хәниф абый. Эше дә гел кешеләр үзәгендә булгач, төркемләп йөрүләрне өнәми. Җәен хатынын да ияртә. Иң зур уңышларын барласаң, балыкчының кармагына 10 килолы сазан, эре чуртаннар эләккәләгән.

– Шөгылебезнең шул ягы яхшы: министрмы син, гади көтүчеме – балыкка барыбер. Монда тигезлек хөкем сөрә. «Мин килдем, кап!» – дип кенә булмый. Спорт дисәң, спортның гадел төре ул, – ди Хәниф абый.

Рәмзия Мифтахетдинова үзен бары тик кышкы балыкчы дип саный. Җәен кармак салмый, ә кышын елга буеннан алып кайтып булмый аны. Балык тоту белән егерме елдан артык мавыга. Кышкы чорда 20–30 тапкыр балык тотарга чыга ул. Яше биш дистәдән арткан инде үзенең. Хәзер менә оныгын да балык тотарга өйрәтә.

– Аңа бик ошый, әкренләп ияләштерәм. Үземнең дә тәүге балык тоткан чагым истә. Ул көнне 7 сыла балыгы эләккән иде, – ди ул. – Тоткан балыкны ирем белән ыслыйбыз йә туган-тумача, балалардыбызга бирәбез. Бик сирәк очракта гына кыздырабыз. Балык тоту үзе дә җиңел шөгыль түгел. Моңа өстәп чыгымлы да. Әйтик, боз өстендә күпме утырасын исәпкә алып, кием-салымны кайгыртырга кирәк. Җылы өс киеме гадәттә 15–19 мең сумга төшә. Салкын температурага чыдам аяк киеме 2700 сум тора. Иң арзан кармак – 500 сум, алдавыч (блесна) 80 сумнан башланып 1000–1500 сумга җитә. Ярга чыкканда ырым-шырымнарга таянмыйм, ышанмыйм. Теләсә нинди һава торышы булганда да балыкка барабыз. Төп кагыйдәм – боз калынлыгы 7 сантиметрдан да ким булмасын. Куркынычсызлыкны кайгыртырга кирәк.

Мәҗлесләр алып баручы Айдар Галиәсҗаров туган ягына якын-тирәдәге сулыкларда кармак салырга ярата. Балачакта һәр малай-шалай кебек үк кызык өчен балык тотарга йөрсә, соңгы ике елда инде чынлап торып асылына төшенеп мавыга икән. Кышын күбрәк Камага һәм Нократ елгасына бара. Анда үзе кебекләр күп, аралашырга да була, күңелле, ди.

– Кечкенә чакта балык тоту белән хәзергесе арасында аерма зур. Элегрәк, азрак «салып алырга» ярата торганнарны балыкка йөри, дип әйтәләр иде. Хәзер балык тотуга башка караш, – дип саный Айдар. – Үзем генә дә йөргәлим. Иптәш егетләр белән дә баргалыйм. Кышкы балык тоту сезонында ялгызың гына боз өстендә утыру бик үк дөрес түгел. Нинди генә хәл булмас та, табигатьнең, һава торышының нинди генә чагы туры килмәс.

Балык тотканда да чама хисен югалтмаска кирәк, ди һәвәскәр балыкчы. Уңышка да кагыла инде бу. Кышын мактанырлык балык капканы юк әле, ди Айдар. Ә менә көзен кармагына 4 кг авырлыктагы балык эләккән. Иң зур уңышы әлегә шул.

– Балыкның кирәк кадәрен генә алам. Аның бит үз таләпләре бар, – дип аңлатты Айдар. – Ләгән, капчык тутырып балык алып кайткан юк, алай булдыра да алмас идем. Ашарлык кадәре җитә. Әйтик, судак балыгының озынлыгы 40 сантиметрдан артмый икән, аны алырга ярамый. Кечкенәләрен без дә кире җибәрәбез. Берш дигәненә аерым таләп. Анысын күпме куләмдә тотсаң да ярый. Тоткан очракта да, эрерәкләрен алырга тырышабыз. Балыкны саткан юк. Күчтәнәч итеп бирергә яратам. Әти дә, хатыным да балык ярата. Минем артык исем китми. Кәҗәсе түгел, мәзәге кызык, диләр бит әле. Балыкка бару – ял итү, башны кирәкмәгән уйлардан арындыру чарасы ул. Хатын да, бөтен начар энергияңне шунда калдырып кайтасың, ди, шуңа бу шөгылемә каршы килми. Үзенә күрә физик хезмәт, хәрәкәт бит ул. Әйтик, күпме чакрымнар үтелә, боз өстендә тишекләр тишәргә туры килә. Балык тотып утырганда уй-хыялларың, табигать белән бергә каласың. Әлбәттә, балыктан кайткач, буыннар да, тән дә сызлый, арыйсың. Әмма ул – рәхәт ару. Балыксыз кайткан чакларым да була минем.

Бу шөгыльнең чыгымлы булуын да яшерми Айдар.

– Әйткәнемчә, элеккечә гади кармакка балык тоту белән хәзергесен чагыштырырлык түгел. Әлбәттә, чыгымлырак кызыксыну бу. Юрганга карап аякны сузасың инде. Хәзерге заманда сайлау мөмкинлеге зурдан. Әйтик, өс киемен 30 мең сумга да, 10 меңгә дә табарга була. Мин ул кадәр хәстәрләнмим. Өс, аяк киемнәре барысы бергә 12 мең сумлык минем, – ди ул. – Балыкка барганда аякның җылыда булуын кайгыртырга кирәк. Төп кагыйдә әнә шул. Аягың, тәнең туңып утыра икән, бу инде балык тоту түгел.

Борнак авылы егете Айрат Фәйзрахмановны Айдар кебекләрнең остазы дисәң дә буладыр. Балык «чир»ен күпләргә ул йоктырган.

– Балыкка кечкенәдән йөрим, канга сеңгән ул минем. Әмма балык ашамыйм. Вакыт булган саен чыгарга тырышабыз. Кышын – Камага, җәен – Нократка. Вактөяк балыкларны кире суга җибәрәм, эрерәкләрен алып кайтабыз. Саткан да бар. Өләшкән дә. Балык тотарга йөрү – ял итү чарасы, – ди һәвәскәр балыкчы.

Сүз уңаеннан, Борнакта ел саен балыкчылар ярышы оештырылып килә. Балтачта балыкчыларның елдан-ел артуына бу да сәбәпче.

Куркынычсызлык нәрсә белән үлчәнә?

Ел саен Татарстанда 100гә якын урынга ун меңләп балыкчы чыгып утыра. Боз өстендә исән калу кагыйдәләрен яттан белү зыян итмәс үзе. Кармак салулар соңгысы булмасын өчен. Хәер, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының санлы мәгълүматларына күз салсаң, боз өстенә чыккан халыкның саграк булуына ышанырга мөмкиндер. Чагыштыру өчен: республикада 2018–2019 елгы боз кату сезонында 3 кеше үлгән, 33 кешене коткарып кала алганнар. 2017–2018 елда сигез кеше боз астына киткән, 52 кешене коткарганнар. 2014–2015 елда биш кеше үлгән, 163 кеше боздан исән-сау чыккан.

Кармак салу куркыныч тәмамланмасын өчен, коткару хезмәткәрләренең балыкчыларга дигән киңәшләрен истә тотарга кирәк.

Куркынычсыз дип кимендә 7 см калынлыкта булган боз санала. Нык боз үтә күренмәле була. Аксыл бозга ышаныч юк. Боз өстендә йөргәндә дә, тәскә игътибар итәргә кирәк. Әйтик, ул каракар булган саен, юкарак. Боз ныклыгын тикшерәм дип, аңа каты итеп бәрү дә дөрес булмас. Бозга ялгыз гына чыгу да куркыныч. Төркемләп йөргән очракта, 3–5 метр ара саклап атларга кирәк.

Балыкчыга бил каешына бау эләктереп куярга киңәш ителә. Боз астына төшеп киткән очракта, судан тизрәк чыгарырга мөмкинлек бирер ул.

Уңышсызлыкка дучар булып, боз астына китә калсагыз, паникага бирелмәгез. Бозлы су – рәхәт нәрсә түгел, шулай да кеше организмы мондый шартларда 5–7 минут дәвамында тора ала. Коткыга бирелеп, игътибарны туплап булмаячак. Башта бер, аннан икенче аякны чыгарып, ашыкмыйча гына боз өстенә чыгарга мөмкин. Салкында җылыну өчен алкоголь куллану дөрес түгел. Бу кешенең ориентирны югалтуына китерә, үз-үзен тотышы үзгәрә. Җылыну өчен иң яхшысы – кайнар чәй.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ТҮЛӘДЕҢ ДӘ ОНЫТТЫҢ ТҮГЕЛ

САЛЫМ АКЧАСЫН КАЙТАРУ ТУРЫНДА 10 СОРАУГА ҖАВАП

Безнең хезмәт хакыннан башлап, барлык төр керемнәребездән дә акча тотып калына. Күп очракта шушы тотып калынган салым акчасын кире кайтарырга да мөмкин.

Татарстан буенча 6 нчы номерлы районара салым инспекциясенең баш дәүләт салым инспекторы Рәмзия МӨХЕТДИНОВА салым «вычет»ы кайтару белән бәйле сорауларга җавап бирде.

1 Бер ел эчендә фатир сатып, яңасын алсаң, декларация тапшырасы түгел, диләр. Бу чынлап та шулаймы?

• Билгеле булганча, биш елдан кимрәк вакыт дәвамында үз милкең булып торган мөлкәт өчен декларация тапшырырга кирәк. Узган ел бу юнәлештә яңа закон гамәлгә керде. Ике яки аннан да күбрәк балалы гаилә, фатирын сатып, бер ел эчендә зуррак яңа фатир сатып алып, торак шартларын яхшырткан булса, декларация тапшырмый. Алардан аңлатма язуы гына кирәк булачак. Әмма бу мөмкинлектән файдалану өчен, гаиләнең бик күп таләпләр буенча туры килүе кирәк. Бу очракта фатир мәйданы да, гаиләнең башка милке булу-булмау да исәпкә алына. Ипотекага алынган фатир хуҗалары өчен дә яңалык бар. Банк белән Салым хезмәте тарафыннан килешү төзелгән булса, хәзер аларга да кәгазь декларация тапшырырга кирәк булмаячак. Моның өчен кешенең Салым хезмәте сайтында (http://www.nalog.gov.ru/www.nalog.gov.ru) шәхси бите булырга тиеш. Банк кирәкле документларны безгә электрон рәвештә юллый, кеше шәхси кабинет аша үзенә җибәрелгән документларны расларга тиеш була. Аннары салым «вычет»ы акчасының күчкәнен көтәсе кала. Салым декларациясен, гомумән, электрон рәвештә тапшырырга киңәш итәр идем. Болай эшләгәндә ул безнең базада көнендә үк күренәчәк. Кәгазь декларация Салым хезмәте базасында күренсен өчен исә уртача биш көн вакыт кирәк. Салым хезмәте сайтындагы шәхси бит аша хәзер бик күп хезмәтләрдән өйдән чыкмыйча гына да файдаланып була.

2 Быелдан башлап спорт белән шөгыльләнгән өчен түләгән акчаның да 13 процентын кайтарып була?

• Әйе, быелдан башлап төрле фитнес-клубларда, бассейн, спорт залларында шөгыльләнгән өчен түләгән акчадан да салым «вычет»ы кайтарып була. Әмма бу министрлык тарафыннан расланган исемлеккә кергән спорт, сәламәтләндерү оешмаларына гына кагыла. Закон әле быел гына гамәлгә керде. Шуңа күрә 2022 елда сатып алынган юлламалар өчен салым «вычет»ын киләсе елда гына кайтарып булачак.

3 Кайсы төр салым «вычет»ын гомердә бер генә тапкыр, кайсын берничә тапкыр кайтарырга мөмкин?

• Милек «вычет»ын гомердә бер тапкыр гына кайтарып була. Стандарт, социаль, һөнәри «вычет»ларны үз гомереңдә ничә тапкыр кайтарсаң да рөхсәт ителә.

4 Милек «вычет»ын кайтару тәртибе нинди?

• Билгеле булганча, милек бәясенең ике миллион сумыннан «вычет» кайтарып була. Кеше милек өчен түләгән акчасының 260 мең сумын (2 миллион сумның 13 проценты. – **Д.Г.**) кире кайтара ала дигән сүз бу. Һәр календарь елы өчен үзегезнең хезмәт хакыннан тотып калынган салым күләмендә «вычет» алырга мөмкин. Калган сумма да янмый, аны киләсе елларда алып бетерәсе булачак. Ипотека процентлары өчен дә «вычет» кайтарып була. Әмма аны бер объекттан гына кайтарырга мөмкин. Процентлар буенча «вычет»ның максималь күләме – 3 миллион сум. Шул рәвешле шушы ипотека капланганда түләнгән процентларның 390 мең сумын (3 миллионның 13 проценты. – **Д.Г.**) кеше кире кайтара ала булып чыга.

Милек «вычет»ына тиешле сумманы бер объекттан кайтарып бетермәсәң, аны икенчесеннән кайтарып бетерергә була. Әйтик, кеше беренче фатиры өчен шушы максималь ике миллион сумның 1800000 сумыннан гына «вычет» кайтара алган ди. Гомер озынлыгы белән тагын бер фатир ала калса, калган 200 мең сумының милек «вычет»ын ул әнә шуннан кайтарып бетерә алачак. Әмма бу 2014 елның 1 гыйнварыннан соң торак булган кешеләргә генә кагыла. Әлеге закон нәкъ менә шул көннән үз көченә керде. Әгәр мөлкәткә 2014 елның 1 гыйнварына кадәр ия булгансыз икән, салым «вычет»ына гомер эчендә бер генә мәртәбә дәгъва кыла аласыз.

5 Милек «вычет»ын ир дә, хатын да кайтара аламы?

• Әйе, кайтара ала. Моның өчен алар икесе дә милек хуҗасы булырга тиеш. Икесенең берсе генә милек хуҗасы булып, ул инде үз гомерендә бер тапкыр милек «вычет»ы алган булса, хәзерге милек өчен бу «вычет»ны ир яки хатын гына да кайтара ала. Бу очракта инде аның милек хуҗасы булып теркәлгәнме-юкмы икәнлеге мөһим түгел. Әмма моның өчен алар иң элек өлешләрне бүлешү турында гариза язарга тиеш.

МИЛЕК «ВЫЧЕТ»ЫН КАЙТАРУ ТӘРТИБЕ

✓ Милек «вычет»ына дәгъва кылган кеше рәсми төстә эшләргә һәм торак аның исемендә булырга тиеш.

✓ Иң элек соңгы ел өчен декларация тутырырга кирәк.

✓ Декларация белән бергә эш урыныннан 2НДФЛ белешмәсе, фатир алганны яки йорт төзүне раслаучы белешмә, сату-алу килешүе, шартнамә, Теркәү палатасыннан күчерелмә, түләү кәгазьләре кирәк булачак. Әлеге документларны салым түләүче теркәлгән урыны буенча урнашкан салым оешмасына тапшырырга тиеш.

✓ Салым «вычет»ы документлар тапшырганда күрсәтелгән исәп-хисап счетына дүрт ай эчендә күчәргә тиеш. Шул вакыт эчендә акча күчмәсә, салым оешмасына мөрәҗәгать итеп, тоткарлыкның сәбәбен белешергә кирәк.



Илдар Мөхәммәтҗанов

6 Пенсионерларга да милек «вычет»ы биреләме?

• 2012 елның 1 гыйнварыннан лаеклы ялдагылар файдасына яңа тәртип кертелде. Хәзер пенсионер милек «вычет»ын узган елларда эшләве өчен сорый ала. Әмма монда өч елдан да күбрәк чигенергә ярамый. Пенсионер кайчан торак алган булса да, күпчелек очракта, соңгы дүрт календарь елы өчен салым «вычет»ы алырга мөмкин. Димәк, 2022 елда ул 2021, 2019, 2018, 2017 еллар өчен салымының бер өлешен кире кайтара ала. Әмма бу эшләүче пенсионерларга гына кагыла. Бу очракта салым оешмасына барлык кирәкле документлар белән бергә пенсия таныклыгы күчермәсен дә тапшырырга кирәк булачак.

7 Социаль «вычет»ка кемнәр дәгъва итә ала?

• Социаль «вычет»ны кайтару түләп дәваланучы, түләп укучыларга каралган. Әйтик, кеше үзен, балигъ булмаган баласын, ирен яки хатынын, әти-әнисен дәвалау өчен тотылган сумма, кирәкле дару һәм препаратлар сатып алу өчен сарыф ителгән акчадан «вычет» сорарга мөмкин. Түләп дәваланганда кайтарыла торган «вычет» ике төргә бүленә. Гади дәвалану вакытында кайтарыла торган социаль «вычет»ның күләме чикләнгән. Ул салым елына 120 мең сумны тәшкил итә. Димәк, кире кайтарып була торган максималь сумма 15600 сумга тигез. Медицина оешмасыннан бирелгән белешмәдә авыруга күрсәтелгән хезмәт коды «кыйммәтле» дип күрсәтелгән булса, аның өчен кайтарып булган «вычет» күләме чикләнмәгән. 150 мең, 200 мең сумнан да социаль «вычет» кайтарырга мөмкин. Түләгән акчаның салым «вычет»ын алу срогы – өч ел.

8 Укыган өчен акчаны ничек кире кайтарырга?

• Моның өчен эшләмәүче студент көндезге бүлектә, эшләүчесе кичке яки читтән торып уку бүлегендә укырга тиеш. Көндезге бүлектә укучы баласы өчен «вычет»ны әти-әнисе кайтара. Түләп укыган өчен кайтарылган «вычет» күләме бер балага 50 мең сумнан да артмый. Баланың укуына түләү өчен ана капиталы акчасы тотылган булса, салым «вычет»ы кайтарылмый. Сүз уңаеннан, музыка мәктәбе, автомәктәптә укыган өчен дә салым «вычет»ы кайтарырга мөмкин.

Шунысын да әйтергә кирәк, ир белән хатын бер-берсенең укуы өчен салым «вычет»ы кайтара алмый. Ә менә абый белән сеңел, апа белән энекәш бер-берсенең укуы өчен «вычет» кайтара алалар.

9 Стандарт «вычет»ны кемнәр кайтара ала?

• Стандарт «вычет»ларны балигъ булмаган балалары яисә көндезге бүлектә белем алучы 24 яшькә кадәрге балалары булган ата-аналар, опекуннар, попечительләр кайтара ала. Ул эш урыныннан бирелә. Моның өчен бухгалтериягә баланың туу турында таныклыгын тапшырып, гариза язарга кирәк. Аның нигезендә, хезмәт хакыннан тотып калынган салымнан беренче-икенче балага – айга 1400 сум, өченче балага 3 мең сум «вычет» түләнергә тиеш. Беренче-икенче инвалид балаларга бу акча – 13400 сум, өченче һәм аннан соңгы авыру балаларга 15 мең сум тәшкил итә. Әгәр бу акчаны эш урыныннан бирмәсәләр, кеше аны декларация нигезендә салым органы аша кайтара ала. Ел дәвамында керем 350 мең сумнан артса, стандарт «вычет» бирелми. Шулай ук стандарт «вычет»ларны кайтару Чернобыльдә, блокадада булганнарга, инвалидларга да каралган.

10 Һөнәри «вычет» дигәндә нәрсә күздә тотыла?

• Бу очракта һөнәри «вычет» турында сүз бара. Аны шәхси эшмәкәрләр, үзләренә эшләүче адвокатлар, нотариуслар, фән, әдәбият, сәнгать өлкәсендә бүләкләнүчеләр, ачыш ясаучы авторлар кайтара ала. Әмма аңа дәгъва итү өчен алар керемнәреннән 13 процентын түләп барырга тиеш. Әйтик, шәхси эшмәкәр, гади система белән эшләп, салымны 6 процент күләмендә генә түләп барган икән, ул әлеге «вычет»ка өметләнә алмый.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

14 февраль | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00, 02.50 «СИҢА КАЙТАМ» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00, 01.10 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Черное озеро» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15, 19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
18.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+

1 КАНАЛ

04.05 Олимпийские зимние игры 2022 г. в Пекине. Фигурное катание. Танцы (произвольный танец) (S)
07.50, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК» (S) 16+
23.25 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 «Познер» 16+
01.05 Дневник Олимпийских зимних игр 2022 г. в Пекине (S) 0+
02.00 «Время покажет» 16+
03.00 Новости
03.05 «Время покажет» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 «КАРИНА КРАСНАЯ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ХОЛОДНЫЕ БЕРЕГА. ВОЗВРАЩЕНИЕ» 16+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 XXIV Зимние Олимпийские игры в Пекине
04.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 XXIV Зимние Олимпийские игры. Кёрлинг. Женщины. Россия – Канада. Прямая трансляция.
06.45, 11.55, 18.35, 21.30, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
07.05, 17.45 XXIV Зимние Олимпийские игры. Хоккей. Женщины. 1/2 финала. Прямая трансляция
09.25 XXIV Зимние Олимпийские игры. Кёрлинг. Мужчины. Россия – Швеция. Прямая трансляция
11.50, 18.30, 22.50 Новости
12.25, 19.25, 22.55 XXIV Зимние Олимпийские игры 0+
13.55 XXIV Зимние Олимпийские игры. Фристайл. Акробатика. Женщины. Финал. Прямая трансляция
15.10 XXIV Зимние Олимпийские игры. Прыжки с трамплина. К125. Мужчины. Командное первенство. Прямая трансляция
15.45 XXIV Зимние Олимпийские игры. Кёрлинг. Женщины. Россия – Дания. Прямая трансляция.
22.20 Тотальный футбол 12+
01.55 Баскетбол. Чемпионат мира-2022. Квалификационный турнир. Женщины. Россия – Пуэрто-Рико. Прямая трансляция
03.55 Новости 0+
04.00 XXIV Зимние Олимпийские игры. Кёрлинг. Мужчины. Россия – Норвегия. Прямая трансляция

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 20.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ЗОЛОТО» (S) 16+
23.35 «ПЁС» (S) 16+
03.05 Их нравы 0+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Позор рода» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «ЖЕМЧУЖНАЯ СВАДЬБА» 16+
19.00 «ДЕНЬ СВЯТОГО ВАЛЕНТИНА» 16+
23.30 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2» 16+
01.25 «Понять. Простить» 16+
02.25 «Порча» 16+
02.50 «Знахарка» 16+
03.15 «Верну любимого» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «МУР ЕСТЬ МУР!-2» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня 16+
09.20 «АЛЫЕ ПАРУСА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2» 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Миссия в Афганистане. Первая схватка с терроризмом». Док. сериал. «Афганистан, 1979 год» 16+
19.40 «Скрытые угрозы». «Альманах № 91» 16+
20.25 «Загадки века». Док. сериал. «Казахстан, который мы не знаем». Премьера! 12+
23.05 «Между тем». Премьера! 12+
23.40 «МАРШ БРОСОК. ОСОБЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА» 16+
03.00 «Бастионы России». Док. сериал 12+
03.50 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2» 16+

15 февраль | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00, 02.50 «СИҢА КАЙТАМ» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар». Муса Җәлил 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники». Муса Джалиль. Возвращение поэта 12+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники» 12+
00.50 «Черное озеро» 16+
01.15 «Реквизиты былой суеты» 12+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15, 19.10, 21.55, 02.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
18.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
13.30 Олимпийские зимние игры 2022 г. в Пекине. Фигурное катание. Женщины (короткая программа) (S)
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК» (S) 16+
22.35 Премьера сезона. «Док-ток» 16+
23.30 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 Дневник Олимпийских зимних игр 2022 г. в Пекине (S) 0+
01.10 Олимпийские зимние игры 2022 г. в Пекине (S) 0+
02.00 «Время покажет» 16+
03.00 Новости
03.05 «Модный приговор» 6+
03.55 «Мужское/Женское» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.55 XXIV Зимние Олимпийские игры в Пекине. Биатлон. Мужчины 4х7,5 км. Эстафета
13.30 «КАРИНА КРАСНАЯ» 16+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ХОЛОДНЫЕ БЕРЕГА. ВОЗВРАЩЕНИЕ» 16+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 XXIV Зимние Олимпийские игры в Пекине
04.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 XXIV Зимние Олимпийские игры. Кёрлинг. Мужчины. Россия – Норвегия. Прямая трансляция
06.45, 18.35, 21.50, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
07.05, 11.50, 17.45 XXIV Зимние Олимпийские игры. Хоккей. Мужчины. Плей-офф. Прямая трансляция
09.25 XXIV Зимние Олимпийские игры. Конькобежный спорт. Командная гонка преследования. Прямая трансляция
13.55 XXIV Зимние Олимпийские игры. Лыжное двоеборье. Лыжная гонка. 10 км. Прямая трансляция
14.35 XXIV Зимние Олимпийские игры. Фристайл. Акробатика. Мужчины. Прямая трансляция
15.10 XXIV Зимние Олимпийские игры. Кёрлинг. Мужчины. Россия – Канада. Прямая трансляция
18.30, 22.40 Новости
19.25, 03.45 XXIV Зимние Олимпийские игры 0+
22.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. ПСЖ (Франция) – «Реал». (Мадрид, Испания). Прямая трансляция
01.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Спортинг» (Португалия) – «Манчестер Сити» (Англия) 0+
03.40 Новости 0+
05.10 XXIV Зимние Олимпийские игры. Горнолыжный спорт. Слалом. Мужчины. Прямая трансляция

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «ЗОЛОТО» (S) 16+
23.35 «ПЁС» (S) 16+
03.25 «ТРИ ЗВЕЗДЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.10 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Обречённая» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «ОКОНЧАТЕЛЬНЫЙ ПРИГОВОР» 16+
19.00 «СЛАБОЕ ЗВЕНО» 16+
23.30 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2» 16+
01.25 «Понять. Простить» 16+
02.25 «Порча» 16+
02.50 «Знахарка» 16+

ЗВЕЗДА

05.20, 14.05, 03.50 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня 16+
09.20 «ДОБРОВОЛЬЦЫ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Миссия в Афганистане. Первая схватка с терроризмом» 16+
19.40 «Легенды армии»в 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
23.35 «1418 шагов к Победе». Док. фильм 12+
00.00 «ЖАРКОЕ ЛЕТО В КАБУЛЕ» 16+
01.35 «НЕПОБЕДИМЫЙ» 12+
02.50 «Бастионы России» 12+
03.35 «Оружие Победы» 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 14–20 ФЕВРАЛЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Җитәкчегез белән әйбәт мөнәсәбәтләр акча агын җайга салырга ярдәм итәр. Әлбәттә инде, яхшы эшләвегез нәтиҗәсе бу. Шул ук вакытта кайберәүләр үзегезне күрмәмешкә салыша башлар. Көнчелектән шулай…

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Гаиләдә дә, эштә дә – тәртип. Бик катлаулы бер мәсьәләне хәл итүдә сөйкемле, тәмле телле булуыгызның ярдәме тияр. Аз гына алдашып алу максатыгызга ирешү мөмкинлеге бирер. Ләкин бу ысулдан еш файдалану юньлегә илтмәс.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Офыкта бурычны яки кредитны каплау мөмкинлеге шәйләнер. Гомумән, атнаның беренче яртысы бик-бик уңышлы узар. Ә менә икенче яртысында кечкенә генә хата аркасында кыенлыклар чыгарга мөмкин. Шуңа күрә үтә игътибарлы булу кирәк.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Хаклы булуыгызны расларга маташып, вакыт әрәм итмәгез. Нәтиҗәсез һәм файдасыз бу хәзер. Белеп торыгыз: кечкенә генә хәйлә уңайсыз хәлдән чыгуга ярдәм итәчәк. Ял көннәрендә туганнарыгыздан әйбәт хәбәрләр ишетеләчәк.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Матди хәлегез кыенлыклардан чыгу осталыгына бәйле булыр. Курыкмагыз: югалып калмаячаксыз! Өстәвенә әле мираска яки салымга кагылышлы күптәнге бер проблемагыз да көтелмәгәнчә бик җиңел хәл ителеп куячак.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Матди якны уйлау, керемнәрне арттыру өчен бик үк уңайлы чор түгел. Мая туплау урынына акчаны туздыру теләге көчлерәк булыр. Хафаланасы юк: озакламый һич көтелмәгән җирдән акча эшләү мөмкинлекләре килеп чыгар.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Тормышыгызда көтелмәгән вакыйгаларга әзер торыгыз. Әйтергә кирәк, күңелле вакыйгаларга. Атна ахырларында дөрес туклануга күчү теләге туар. Теләк кенә түгел, мөмкинлек тә пәйда булыр!

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Шәхси тормышыгыз тел-теш тидергесез дәрәҗәдә көйле барыр. Акчасы да, башка шатлык-сөенечләре дә булыр. Ләкин менә эштәге бер проблема гына күңелегезне тырнап торыр…

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Нәрсәгә генә тотынсагыз да, әҗәрен бик тиз күрәчәксез. Шуңа күрә үзегез өчен иң мөһимнәрен сайлап алыгыз да, алга! Мая туплый башлау өчен әйбәт чор: акчаның бик шәп кергән чагы чөнки.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Белеп торыгыз: һавалырак булуыгыз якыннарыгызга зыян салырга мөмкин. Бу атнада эшегездә ялтырап алу мөмкинлеге барлыкка килер. Кулдан ычкындырмагыз шуны!

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Яңа керем чыганаклары пәйда булуга сөенеп туя алмассыз. Атна урталарында ишетелгән бер хәбәр, бер яктан, сөендерсә, икенче яктан, кызык кына уйлануларга этәрер. Инде килеп, дустыгызның вәгъдәсе буш куык кына булып чыгар.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Ирешелгән уңышлардан башыгыз әйләнеп китмәсен, юкса алардан коры калуыгыз бар. Күктән җиргә төшегез, дип киңәш итә йолдызлар. Ял көннәрендә бик зур шатлык-куанычлар кичерү мөмкинлеге бирердәй хәл килеп чыгар.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы, улы – Ерак Көнчыгыш һәм Арктиканы үстерү Корпорациясе генераль директоры

НОСОВ
Игорь Николаевичның

вакытсыз вафат булуы сәбәпле, сәхнәдәшебез, дустыбыз, Татарстан Республикасының халык артисткасы Искәндәрова Хәлимә Шакир кызының, гаиләсенең, туганнарының һәм дусларының тирән кайгысын уртаклаша. Ходай Сезгә хәсрәтегезне күтәрә алырдай көч, сабырлык бирсен!

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ТАМАК АВЫРТУНЫ САЛКЫН СУ БАСА

Тамак авырту – һәркайсыбызга таныш халәт. Бик күп чирләрнең юлдашы ул. Соңгы арада тамак авырту турында аеруча күп сөйләнә. Ник дигәндә, хәзер коронавирус та тамак авыртудан башлана, ди белгечләр. Тавыш карлыгу да коронавирус билгесенә әверелә башлаган. Гадәти тамак авырту коронавирус вакытында күзәтелгән авыртудан аерыламы? Аны ничек дәваларга?

Шул сораулар белән табиб-отоларинголог Айгөл ГАЗИЗОВАга мөрәҗәгать иттек.

:: Айгөл Илдаровна, тамак авырту нинди чирләр турында кисәтә ала?

– Тамак авырту йоткылыкның арткы стенкалары яки миндальсыман бизләрнең ялкынсынуыннан барлыкка килә. Ул хроник тонзиллит баш калкыту аркасында да борчый ала. Тамак ГЭРБ (гастроэзофагеаль рефлюкс авыруы) дип исемләнгән ашказаны-эчәк чире аркасында да авыртырга мөмкин. Аны еш кына фарингит белән бутыйлар. ГЭРБ вакытында тамакка төер утырган кебек тә тоелырга мөмкин. Шуңа күрә андый билге күзәтелгәндә, иң элек отоларингологка, аннары гастроэнтерологка күренергә кирәк. Алга таба эндокринолог белән психотерапевтка да мөрәҗәгать итәргә туры килүе ихтимал. Ник дигәндә, еш кына психик авырулар да тамакка төер утырган кебек билгедән башлана.

:: Коронавирусның «омикрон» штаммын йоктырган кешенең дә иң беренче чиратта тамагы авырта башлый, диләр. Ковид вакытындагы тамак авырту гадәти тамак авыртудан аерыламы?

– Юк, бернәрсә белән дә аерылмый. Коронавирус вакытында да, ОРВИ йоктыручыда да тамакның бер үк төрле авыртуы күзәтелә.

:: Тамак авыртканда, туңдырма, салкын су ярдәм итә, диючеләр хаклымы?

– Туңдырма белән салкын су, дөрестән дә, тамак авыртуны баса. Әйткәнемчә, тамак авырту ялкынсыну аркасында килеп чыга. Ялкынсыну вакытында исә кан тамырлары киңәя. Салкын су эчкәндә, туңдырма ашаганда алар кысыла, кан әйләнеше акрыная. Нәтиҗәдә, кеше тамак авыртуны да җиңелрәк кичерә.

:: Тамакны ничек дәваларга?

– Дәвалауда һәркемнең үзенә килешкән алымы була. Бер кешегә килешкән чара икенчесенә бөтенләй файда китермәскә мөмкин. Шуңа күрә тамак авыртканда, иң элек үзегезгә килешкән дәвалау ысулларына өстенлек бирегез. Күпләр бу очракта суыра торган төймәләр куллануны тырыша. Әйе, алар да ярдәм итә. Әмма бу төймәләрнең тамак авыртуны ни дәрәҗәдә басуы селәгәйнең күпме бүленеп чыгуына бәйле. Ул күбрәк бүленеп чыккан саен, бу төр даруларның да файдасы зуррак була. Тамакны тоз һәм сода эремәсе белән чайкау да ярдәм итә. Өч көн дәвамында авырту кими төшсә, бик яхшы. Әгәр шушы өч көн эчендә тамак, киресенчә, катырак авыртса, температура күтәрелсә, авызны ачу кыенлашса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Авырткан тамакны җылытырга ярыймы?

– Болай эшләргә киңәш итмәс идем. Ник дигәндә, миндальсыман биз белән йоткылык мускуллары арасында үлек (паратонзилляр абсцесс) булса, тамакны җылытканда ул артачак кына. Бу чир бик авыр һәм озак дәвалана, кешенең үзенә дә бик зур кыенлыклар тудыра.

:: Даими рәвештә тамагы авыртып интеккән кешенең тора-бара тавышы да үзгәрә, диләр. Бу сүзләр дөреслеккә туры киләме?

– Ул күбрәк өске сулыш юллары ялкынсынганда (ларингит) күзәтелә. Ларингит вакытында тавыш карлыга. Шушы авырудан соң кешенең тавышы да үзгәреп калырга мөмкин. Шуңа күрә бу чирне дәвалауга бармак аша карарга ярамый.

:: Нинди киңәшләрне истә тотарга кирәк?

– Иң беренче чиратта авыз куышлыгындагы хроник инфекция чыганакларын (кариес, хроник тонзиллит) юкка чыгарырга кирәк. Кеше туңганда, организмның вирусларга каршы торучанлыгы кими. Тешендә кариес булган, хроник тонзиллиттан интеккән кешеләр исә вирусларга аеруча еш бирешә. Гадәттә, алар иң нәзберек урынга – тамакка бәрә.

Белеп тор!

Ингаляция ясау тыела!

Тамак авыртуның беренче билгеләре сизелүгә үк, күпләр ингаляция ясау белән мавыга. Бәрәңге парын сулаучылар да очрый. Әмма тамак шешкәндә пар ингаляцияләре ясарга ярамый, дип кисәтә белгечләр. Җылылык аркасында шешү көчәя һәм кешенең тыны бетәргә мөмкин. Шулай ук тән температурасы 37,5 градустан югары булганда да ингаляцияләр ясарга ярамый, ул да ялкынсынуны арттыра.

Үзем сынадым

Чөгендер булышты

Тамак авыртканда чөгендер төнәтмәсенең файдасын күрдем әле. Кыргычта уылган бер стакан кызыл чөгендергә бер аш кашыгы аш серкәсе салып төнәтәсең дә соңыннан шуны сыгып, тамакны чайкатасың. Бер-ике кашык йотып куйсаң да зыян юк. Ике көндә тамакны рәтләдем.

Әлфия САБИРОВА. Казан

Киңәш-табыш

Кан тамырлары киңәюдән саклый

Шифалы мазь. 10 грамм ромашка чәчәгенә шалфей яфрагы белән чәчәге, 50 г ат кәстәнәсе агачының төелгән чикләвеге, 5 г бәрәңге крахмалы кушып болгатыгыз. Шулар өстенә 200 г кайнар тавык шулпасы салыгыз да, савытны сүрән утта кайнап торган сулы кәстрүлгә утыртып, 2,5 сәгать тотыгыз. Төн чыккач, әлеге катнашманы кайный башлаганчы утта тотып, суын саркытыгыз. Суынгач, аягыгызга сөртегез.

Помидор. Пешкән помидорны кисәкләп турагыз да киңәйгән аяк тамырларына каплап, чеметтерә башлаганчы тотыгыз. Помидорларны алгач, аякларны салкын су белән чайкап куярга онытмагыз. Дәвалану процедурасын тамыр зәңгәрлеге беткәнче эшләргә кирәк.

Әрем. Бер уч төелгән әрем яфрагы белән орлыгын ярты литр оеган сөткә салып болгатыгыз. Шул боламыкны 3–4 кат марлядан ясалган салфеткага сылап, аякның киңәйгән тамырларына каплагыз. Өстенә полиэтилен ябыгыз да, аякны кечкенә мендәргә сузып куеп, ярты сәгать утырыгыз.

Исеңдә тот

БАЛНЫҢ ФАЙДАСЫ БАР

Бал нерв системасын бик яхшы тынычландыра һәм организмда мелатонин гормоны эшләп чыгарылуга ярдәм итә. Ул тыныч йокы өчен җавап бирә һәм йокы вакытында куәнәкләрне яңарта. Йоклар алдыннан 1 аш кашыгы бал ашасагыз һәм бер стакан ромашка чәе эчсәгез, стресс сезгә куркыныч түгел. Моннан тыш бал артык авырлыктан котылырга да ярдәм итә. Соңгы тикшеренүләр даими рәвештә бал кулланган кешеләрнең артык килограммнардан тиз арада арынуын исбатлаган. Бал, бигрәк тә шикәрне аның белән алыштырсаң, матдәләр алмашын яхшыртуга ярдәм итә. Физик күнегүләр вакытында калорияләрне яндыру да 10 тапкыр җиңелрәк.

---

pixabay.com

Салкыны да шифалы

Салкын көннәре белән күпләрнең күңеленә ятмаса да, кыш сәламәтлегебез өчен иң файдалы чор санала.

Кышкы һава файдасы буенча диңгез һавасыннан бер дә калышмый! Кышкы һавада кислород җәйгегенә караганда 30 процентка күбрәк, дип ышандыра галимнәр. Өстәвенә салкын көннәрдә һава тузаннан һәм зарарлы кисәкчәләрдән дә чистара.

Кышын саф һавада йөгерү җәйгегә караганда фигура өчен күпкә нәтиҗәлерәк булачак. Тикшеренүләр күрсәтүенчә, салкында 15 минут күнегүләр ясау җәйге бер сәгатьлек күнегүләрне алмаштыра.

Салкында кан әйләнеше, метаболизм яхшыра, организмда бәхет гормоны (серотонин) һәм эндорфиннар бүленеп чыга. Болар тән тиресенә уңай йогынты ясый.

Салкын һаваның күңелне күтәрүе, дәрт өстәве дә фәнни яктан күптән расланган. Салкынча бинада эшләүче кешеләр, җылыда утыручыларга караганда, алларына куелган бурычларны яхшырак үти икән.

Ак төс – иң яхшы психолог. Ул агрессияне киметергә сәләтле.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Матурлык

Яшәртә торган битлек

Кыш көне бит тирегез төссезләнеп, бераз шәлперәеп тә киткән булса, әлеге битлекне ясап карагыз.

Аның өчен берәр чәй кашыгы вакланган солы лачаулары (хлопья), бал һәм зәйтүн мае кирәк булачак. Аларның барысын да яхшылап болгатыра һәм битлекне чиста биткә сылап, 15 минут торырга кирәк. Атнага ике тапкыр кулланган очракта бер-ике атнадан нәтиҗәсен күрми калмассыз.

Үзем сынадым

Микродулкынлы мич агарта

Интернетта ак оекбашларны микродулкынлы мичтә агартып була дип укыган идем, шуны сынап карадым. Ак оекбашларның каралган үкчәсен һәм табанын агарту өчен, аларны җылы суда юешләп, яхшылап кер сабыны белән ышкырга кирәк. Аннары пакетка салып, 1000 Вт егәрлектә 3 минутка куярга. Берничә оекбашны тиз арада агарту өчен бик шәп ысул икән. Оекбашлар ап-ак булды.

Алсу ЗАРИПОВА. Яшел Үзән

«КИЛЕН»ГӘ ИПТӘШ САЙЛЫЙБЫЗ

Халык телендә «килен» дип йөртелгән кер юу машинасына иптәшкә «икенче килен» дә аш бүлмәсе түрендә урын алды. Хәзер күпчелек хуҗабикәләр савыт-саба юуны да машинага тапшырды. Рәхәткә тизияләшәсең бит! Хатын-кызның ярты гомере савыт-саба юып үтә, дип юкка гына әйтмиләр. «Ирләрнең тыныч һәм рәхәт яшиселәре килсә, хатыннарына савыт-саба юу машинасы алсыннар», – дип шаярта көнкүреш техникасы сату челтәре консультанты Радик Гыйльмиев.

Ул безгә савыт-саба юу машинасын сайлау һәм куллану буенча киңәшләрен бирде.

Киңенме әллә тарынмы?

Савыт-саба юу машинасын аш бүлмәсенең зурлыгына карап сайларга кирәк.

Зур булмаган кухня өчен 45 см киңлектәге машина туры килә, әмма мәйдан зуррак булса, 60 см киңлектәге тулы үлчәмле машина кую яхшырак. Ә 55 см киңлектәге компакт машина (идәнгә түгел, киштәгә куела) еш кына ике кешедән торган гаилә өчен дә җитәрлек булмаска мөмкин. Тар модельгә савыт-сабаны салу һәм аннан алу кыенрак. Су һәм электр энергиясен ул да тулы размерлысы кебек үк сарыф итә.

Эчкә кертеп куелганымы әллә аерым торганымы?

Савыт-саба юа торган машина сайлаганда, гарнитур эченә кертеп урнаштырыла торганымы, әллә аерым куела торганы кулайракмы икәнлеген хәл итегез. Аерым куела торган машиналарны сайлау кыенлык тудырмый. Алар теләсә кайсы аш бүлмәсенә сыялар, күбесенчә ишекләре үтә күренмәле була. Мондый төр юа торган машинаны төрле бәягә табарга була. Тагын бер яхшы ягы – кухня гарнитурын аны кую өчен көйләргә кирәкми. Әгәр күченеп китсәгез, үзегез белән дә алырга мөмкин. Тик алар кухня дизайнында бик үк матур күренмәскә мөмкин. Тагын бер кимчелеге – юу сыйфаты ягыннан көндәшенә караганда калыша.

Ничек экономияләргә?

Электр энергиясен азрак сарыф итү өчен эко режимын кулланыгыз. Әлеге режимда машина озаграк эшли, әмма су һәм электр энергиясен янга калдыру мөмкинлеге бирә. Төп режимда эшләтү белән чагыштырганда 30 процентка якын экономия булачак. Шулай ук машинаны дөрес тутыру да мөһим. Савыт-саба күп җыелды дип, артыгын тутырырга тырышмагыз. Эре әйберләрне ян-якка куярга киңәш ителә. Зур тәлинкәләрне алга тезмәгез, чөнки кәрзин артындагы савыт-саба тиешенчә юылып бетмәячәк. Энергияне төнге куллану тарифы булса, савыт-сабаны төнлә юарга тырышыгыз. Бу да шактый акчаны янга калдырачак.

Тәмле булсын!

Мандаринлы уалучан пирог

Камыр өчен кирәк:

- он – 250 г
- камыр көпшәкләндергеч – 1 чәй кашыгы
- йомырка – 1 данә
- шикәр комы – 100 г
- атланмай – 150 г



Эчлек:

- мандарин – 6–7 данә
- Шикәр комы – 100 г
- Он – 50 г

Әзер уалучан камырның яртысын табаның төбенә җәябез. Туралган мандаринны шикәр комы һәм он белән болгатып, камыр өстенә салабыз. Аның өстенә калган камырны бик каты басмый гына таратып чыгабыз һәм 180 градуслы мичкә 20–25 минутка озатабыз. Бик тәмле була!

Әти-әниләргә

ӘЙТМӘ СИН...

Мөнәсәбәтләрне җайлау өчен дә, бозу өчен дә бер сүз җитә. Бигрәк тә әти-әни белән әле психикасы ныгып бетмәгән бала арасында упкын булмасын өчен, сүзләрне бик сак кулланырга киңәш итә психологлар. Түбәндәге җөмләләрне, гомумән, кулланудан төшереп калдырсагыз, яхшырак булачак.

1. «СИН БУЛДЫРА АЛМЫЙСЫҢ»

Әлеге сүз белән балага аның көченә ышанмавыбызны күрсәтәбез. Аңа ошый торган нәрсәне эшләп карау мөмкинлегеннән мәхрүм итәбез. Шушы сүзләр баланың канатларын кискәндәй итә.

2. «СИН УЙЛАП ЧЫГАРАСЫҢ» / «МОНДЫЙ ХӘЛ БУЛМАДЫ»

Бу сүзләр белән шулай ук балага ышанмавыбызны белдерәбез, ә аның хатирәләре һәм хисләре ялган булуын исбатлаган төсле булабыз. Бу сүзләрне, гадәттә, токсик кешеләр куллана. Бала тормышында шундый кешеләрнең берсе буласыгыз килмәсә, әлеге сүзне куллланудан тыелыгыз.

3. «ТЕЛӘСӘҢ НӘРСӘ ЭШЛӘ!»

Бер яктан, бу сүзләр нәрсәне дә булса балага ышанып тапшыруны күрсәтә. Әмма, икенче яктан, бала аны безнең тулысынча битараф булуыбыз дип кабул итәргә дә мөмкин. Баланың соравына яки ниндидер фикеренә җавап итеп, әлеге сүзләрне кулланудан сак булыгыз.

4. «ҮЗЕҢ ГАЕПЛЕ»

Гаепләү ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштырырга ярдәм итми. Бәлки бала, чыннан да, ялгыш эшләгәндер. Тик алар өлкәннәрдән гаепләү түгел, ярдәм көтә. Әгәр баланы гел шулай гаепләп торсагыз, ул башка ярдәм сорап мөрәҗәгать итми башларга да мөмкин.

5. «БЕР ЕЛДАН СОҢ СИН БУ ХАКТА ХӘТТА ИСКӘ ДӘ АЛМАЯЧАКСЫҢ»

Әйе, бала, чыннан да, бу хәл турында бер айдан онытыр да. Әмма хәзерге вакытта ул борчыла һәм сезнең тарафтан ярдәмгә өметләнә.

Тиздән онытыр дип, баланың кичерешләренә игътибар бирмәү – зур хата. Бу ике арадагы ышанычны җимерергә мөмкин.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

МИН-МИНЛЕК – АЛЛАҺТАН ЕРАГАЮ «ҖИМЕШЕ»

Коръәни Кәримнең «Локман» сүрәсендә: «Кешеләрдән тәкәбберлек белән йөзеңне борма, Җир йөзендә эрелек белән йөрмә. Раббыбыз Аллаһ һәрбер мактанучы, тәкәбберне яратмый», – диелә. Дин тарафыннан тыелса да, арабызда тәкәббере дә, мактанчыгы да, үзен башкалардан өстен куярга яратучысы да җитәрлек.

Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр эшчәнлеге буенча урынбасары Равил хәзрәт ЗӨФӘРОВ белән әнә шул сыйфатлар турында сөйләштек.

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһиссәлләм бер хәдисендә: «Сезләрдә элгәреге кавемнәрдән калган гадәтләр бар», – дигән. Рәсүлебез монда мактану, икенче бер кешене түбәнсетү, үзеңне эре санау кебек сыйфатлар турында кисәтә. Шуңа күрә бу сыйфатлар диндә кире кагыла. Аларны адәм баласы да яратмый. Бик хәерсез, яман, адәм балаларын бер-берсеннән ерагайта торган, Аллаһы Тәгалә каршында адәм баласының дәрәҗәсен түбән кыла торган сыйфатлар бу.

:: Хәзер социаль челтәрләрдә, бигрәк тә «Инстаграм»да шундый хәл күзәтелә: кеше үзен үтерел мактый. Ул гына булдыра да башкалар җебегән, булмаган дигәнрәк фикерне алга сөрә. Коронавирус вакытында кеше аеруча эмоциональгә әверелде бит. Аларны ишеткәннән соң, болай да үзеннән канәгать булмаган кешеләр үзләрен тагын да түбәнрәк, кирәксез, булдыксыз итеп тоярга мөмкин. Кешенең, үз бәясен күтәреп, башкаларны түбәнсетүенә дин нинди караштa?

– Әгәр кешедә тәкәбберлек, мин-минлек, шапырыну кебек сыйфатлар бар икән, моннан гыйбрәт алырга кирәк. Аларның киң каткауга да тәкъдим ителүе аеруча аяныч. Хәзер бик күп кеше социаль челтәрләрдә тормышы белән бүлешә, хәтта сер булган, яшерен нәрсәләрне ачып сала. Тормышлары нәрсә ашавын, нәрсә киюен, нәрсә алганын күрсәтүгә кайтып кала. Иң гаҗәбе: күп очракта бу кешеләр каршында үзен шундый бер югары, булдыклы итеп күрсәтү өчен эшләнә. Аннан соң кемдер, дөрестән дә, түбәнсенергә мөмкин. Ислам динендә мондый гамәл хупланмый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһиссәлләмнең алып килгән дине – оялу дине. Ул ислам диненең билгесе булып тора. Монда Аллаһ Раббыбыздан оялу күздә тотыла. Пәйгамбәребез, Аллаһыдан оялырга кирәк, дигән вакытта сәхабәләр: «Йә, Рәсүлаллаһ, без бит Аллаһтан оялабыз, Аллаһка шөкер», – дигәч, Пәйгамбәребез: «Аллаһтан хакыйкый оялу шулдыр: башыңда булган нәрсәнең – уйларыңның, фикерләреңнең тәртиптә булуы», – дигән. Ягъни адәм баласының эчендә булган һәр нәрсә тәртиптә булырга тиеш.

:: «Мин» дип шапырынып, ахырдан: «Аллаһка шөкер, мин булдырам», – дию дөресме?

– Мин-минлек – шайтанның сыйфаты. Шул «мин» дигән халәте белән бәхетсезлеккә ирешә дә инде ул. Үзеңне сайлап алынган, аерым бер күркәм, хәерле, югары сыйфатта итеп күрү, Раббыбыз Аллаһны искә алып сөйләгән очракта да, мин-минлек санала. Ислам дине, гомумән, тәкәбберлекне яратмый. Мактанучы, шапырынучы, үзен эре куючылар турында Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримендә: «Мин аларны яратмыйм», – дип хәбәрен бирә. Тәкәбберлек сыйфаты, беренче карашка, бик күренмәскә, беленмәскә дә мөмкин. Әмма эрелек, үзеңне эре тоту әллә каян күзгә ташлана. Мөселманга һич кенә дә килешә торган күренеш түгел бу.

:: Мин-минлек һәркемдә була бит...

– Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримендә: «Адәм баласы зәгыйфь хәлдә яратылды», – ди. Без – зәгыйфьләр, кимчелекле, ялгышабыз, хаталанабыз. Бу сыйфатлар бездә бар, чөнки шайтан да кан тамырларыбызда агып йөри – вәсвәсәсен кыла. Пәйгамбәрләр генә – һәрбер хатадан, кимчелектән азат, хали булган затлар. Без – гади кешеләр. Шуңа да Раббыбыз Аллаһ безгә динен насыйп итте, аның белән зиннәтле кылды. Иманыбыз сәбәпле, Раббыбызның тәрбияче, олуг кодрәт иясе, һәр нәрсәне юктан бар итеп яралтучы икәнен аңлау, Раббыбыз Аллаһы Тәгалә каршына барачагыбызны

pixabay.com

төшенү бездә бу сыйфатларның юкка чыгуына сәбәп була. Нәфесебезне йөгәнләсәк, тәрбияләргә тырышсак һәм инде дөрес юлда булсак, иншаллаһ, яхшылыкларыбыз, игелекләребез бу сыйфатларны тормышыбыздан алачак. Раббыбыз Аллаһ разый булган хәлгә ирешәбез. Әмма бу сыйфатлар үз хәлендә калдырыла икән, шул вакытта артырга мөмкин. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһиссәлләм: «Кеше гөнаһ кылса, күңелендә бер кара тап арта. Ул, күбәя-күбәя, аның күңелен томалап ала», – ди. Шуңа күрә бу сыйфатлардан Раббыбыз Аллаһка дога кылып, аны искә алып: «Йа Раббым Аллам, шул кирәкмәгән сыйфатлардан, яман, әшәке хәлләрдән мине имин, сәламәт кылсаң иде», – дип, без иминлеккә, сәламәтлеккә ирешә алабыз, иншаллаһ.

:: Ни өчен соңгы арада эгоизм, мин-минлек кебек сыйфатлар аеруча еш күзәтелә башлады икән?

– Моңа, иң беренче чиратта, адәм баласының үзенә йомылуы, Раббысы Аллаһ белән бәйләнеше зәгыйфьләнү сәбәпче. Бу дөньяда яшәгән вакытта адәм баласы, хаталанып китеп, шул сыйфатларга ирешә һәм алар тарала. Шул ук социаль челтәрләр, телевидение бу сыйфатларны бигрәк тә матур, күркәм итеп, менә шундый булырга – дөньядан өзеп алырга кирәк, дөньяның кендегә булырга, үзеңне шулай тотарга кирәк дип күрсәтә. Кешедә булырга тиешле күркәм, хәерле сыйфатлар кирәкми, алар җәмгыятькә комачау итә, кешене мескенлеккә, түбән дәрәҗәгә төшерә ала дигән күзаллау урнаша. Чынлыкта, бар да нәкъ киресенчә. Динебез ислам хәер-сәгадәт юлын бирә. Ул юлда алган хәерле тәрбия безне бу сыйфатлардан ерагайта. Бу дөньяда һәркемнең, һәрнәрсәнең хакын хаклап яшәргә өйрәнсәк, бу начар сыйфатлар арабыздан югалыр иде.

:: Мин-минлектән, мактану, масаю гадәтеннән арынып буламы?

– Бу яман сыйфат-гадәтләрдән арыну өчен, иң беренче чиратта, Аллаһ Раббыбызны искә алырга, үзебезнең зәгыйфь, көчсез бәндә икәнебезне танырга кирәк. Раббыбыз Аллаһ – олуг рәхмәт әйләүче. Адашсак, Ул – безгә һидаять бирүче, авырсак, шифа бирүче, ачыксак ризыкландыручы. Раббыбыз Аллаһ – безгә һәр яктан да нигъмәт әйләүче, күркәм сабырлык белән хата-ялгышларыбызны гафу итүче, догаларыбызга җавап бирүче. Адәм баласы Аллаһның нигъмәтләренә шөкрана кылырга тиеш. Аның фарызларын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә кирәк. Элекке заманнарда тәрбия шундый булган: кеше, бай булса да, акчасы, мал-мөлкәте булса да, аны күрсәтергә тырышмаган. Тормышны тәкәбберлек, эрелек, мактану, мал-мөлкәт, әтисенең мөлкәте, җиңел килгән акча белән мактанып, бөтен дөньяга күрсәтеп алып барасы урынга, киресенчә, шөкрана кылып, түбәнчелек белән, Аллаһ Раббыбызның рәхмәтенә, нигъмәтләренә омтылу зарур.

Гыйбрәт өчен

Үзең күрмәгәнгә ышанма!

Көннәрдән бер көнне бер ир кулына кош тоткан. Теге кош, аңа ялварулы караш ташлап: «Кулыңда килеш сиңа бер файдам да тимәс. Әмма иреккә очырсаң, сиңа өч төпле киңәш бирермен!» – дигән. Кошчык беренче киңәшне – ирнең кулында, икенчесен – агач ботагына кунгач, өченчесен тау башында әйтергә вәгъдә биргән.

Ир кеше ул әйткәннәр белән ризалашкан. Кошчык аның кулында килеш беренче киңәшен биргән:

– Дәлилләнмәгән, аек акылга каршы килгән бер генә нәрсәгә дә ышанма! – дигән ул.

Аннан кошчык агач ботагына очып кунган да: «Әй, адәм баласы, син шулкадәр бәхетсез! Мин ике зур бриллиант йоткан идем. Мине харап иткән булсаң, аларны үзеңә алыр идең», – дигән.

Ирнең моңа бик нык ачуы чыга. «Өченче киңәшеңне дә бир инде!» – дип ярсый ул. Кошчык исә:

– Бигрәк юләр син, адәм баласы. Беренче ике киңәшемә колак та салмаган килеш өченче киңәшне сорыйсың. Мин сиңа, аек акыл белән уйлап, дәлилләнмәгән, дөреслеккә туры килмәгән әйберләргә беркайчан да ышанмаска куштым. Ә син, ике дә уйламый, минем шаяртып әйткән сүземә ышандың.

pixabay.com

Минем кебек кечкенә генә кошчык эченә ничек ике бриллиант сыйсын инде?! – дигән дә очып киткән! Тормышта да аек акыллы булып, үзең күргән, үзең тәгаен белгән әйберләргә генә ышану мәслихәт шул.

Белеп тор!

Эч пошканда укыла торган дога

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

«Үә ләһү мә сәкәнә фил-ләйли үән-нәһәрь үә-һүәс-сәмигъуль-гъалим».

Мәгънәсе: «Төнлә яшәгәне дә,көндезен дә – Аллаһныкы. Һәм Ул – ишетүче,белүче».

(«Әл-Әнгам» сүрәсенең 13 нче аяте)

Хәдис

▸ Кешегә башкалар алдында хур булу өчен дүрт нәрсә җитә: бозык булу, каты телле, саран һәм куркак булу.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ФӘРҺАД МӨХӘММӘТҖАНОВ:

«АКТЕРНЫҢ ӘЙТЕР СҮЗЕ БУЛЫРГА ТИЕШ»

Яшьлекнең һәр нәрсәгә үз карашы бар. Сәнгатьтә дә ул башкалардан аерылып торырга тели. Тинчурин театрының яшь артисты, күпләргә «Рәхәт яшибез», «Бер-бер хәл» сериаллары аша таныш булган Фәрһад МӨХӘММӘТҖАНОВ белән әнә шул хакта сөйләштек әле.

:: Ни өчен театр, Фәрһад?

– Мәктәптә укыганда кая барып, кем буласымны үзем дә белми идем. Тугызынчы сыйныфка җиткәч кенә уйланырга туры килде. Тумышым белән Азнакайдан булгач, әти-әнием, геофизик һөнәрен алып, нефтьче булуымны теләде. Акчасы да бар, имеш. Алар белән бик килешеп бетәсе килмәде. Аннан әни дизайн юнәлеше турында сүз кузгатты. Беренче сыйныфтан бирле сәхнәдән төшмәсәм дә, актерлык, сәнгать турында уй башыма да кереп карамады. Мин аны үзем дә эшкә санамадым. Рәхәтләнеп сәхнәдә йөрү эш була аламыни?

Тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, әнигә әйтми генә, геофизик һөнәрен үзләштерергә дип, Әлмәткә барып укырга керергә карар кылдым. Укырга керүемне әнигә шалтыратып әйткәч, шаккатты, билгеле. «Хәзер артка юл юк, керәсеңме соң?» – дип сорагач, аптырап калдым. Акча дип кенә бер дә аяк тартмаган җиргә барасым килмәде. Шуңа да 10 нчы сыйныфка калырга туры килде инде.

Шулай бер ниндидер чарада катнаштым. Шунда миңа: «Бу тавышыңны югалта күрмә! Сиңа сәнгать юлын сайларга кирәк», – диделәр. Ә мин аны уйламаган да идем. Кара әле, мин әйтәм, яхшы фикер бит. Тотындым әзерләнергә. Бар теләгем Казанның мәдәният-сәнгать институтына керү иде. Үземнең наданлыгым аркасындадырмы, ул өлкәдә укучы танышларым булмагангадырмы, театр училищесы турында ишеткән дә юк иде. Бу хакта әни генә әйтте. Шулай итеп, 11 нче сыйныфны укып тормыйча, шунда барырга тәвәккәлләдем. Тәслимә Хәләф кызы курсында укый башладым. Бераз атна узгач, үз урынымны тапканымны аңладым.

:: Гаиләң бик ярдәм иткән икән.

– Әйе, бик булыштылар. Әни, әле мин укырга кергәч тә, бөтен курс белән танышып, безнең өчен һәрвакыт җан атып

торды. Азнакайда гастрольләр оештыручы да, Санкт-Петербургка кадәр алып баручы да ул – булды.

:: Укыганда бу юлны сайлавыңа үкенмәдеңме?

– Юк, үкенмәдем, ләкин, мин чыннан да үз юлымны таптыммы икән, дигән икеләнү булды. Аеруча мастерлардан «Фәрһад, син – нуль» дигән сүзләрне ишеткәндә. Остазыбыз Тәслимә Хәләфовна гел: «Актер өчен иң куркыныч сүз ул «профнепригодный», – дип әйтә килде.

Блиц-сораштыру

– Иң бәхетле көнең?

– Бүген.

– Чәчләрең бөдрә булмаса...

– ...туры булырлар иде, яки мин болай ук хыялый булмас идем.

– Кумирың бармы?

– Остазым мәрхүмә Фәйзуллина Тәслимә Хәләф кызы. Һәм хыялымда яшәүче, киләчәктәге Фәрһад.

– Бүген нинди җыр тыңладың?

– Әлфия Авзалованың «Ник соңладың?» җырын.

– Йөрәгең бушмы?

– Яртылаш. Йөрәк яртылаш иҗат белән тулган, ә яртылаш буш.

:: Укып бетергәнеңә бер ел була гына әле, ләкин шактый проектларда катнашкансың. Һәр яшь актерга мондый мөмкинлекләр булмый.

– Мәдәният хезмәткәре, блогер һәм татар бәйгеләрен оештыручы буларак, нинди дә булса яңалык кертәсе килде. «Инстаграм»ны дөрес алып бару серләренә төшендерү буенча мастер-класста берничә хатын-кызның робагыйларның нәрсә икәнен белмәве шаккатырган иде. 2022 елның Россия халыкларының мәдәни мирасы елы булуы да этәргеч бирде. Татарстанда – Цифрлаштыру елы. Ике куянның койрыгын бергә тотып була бит дип, @tatarka-regina аккаунтында робагыйлар язу бәйгесе оештырырга уйладым. Аңа кадәр язылучыларны робагыйлар белән таныштырдым. Халыкка ошады. Ә мин исә, робагыйлар эчендә кайнавым белән рәхәтлек алдым. Алар бит – шулхәтле мәгънәле, акыл, киңәш бирүче дүртьюллыклар… Озак уйлап тормыйча, бәйге шартларын аңлаттым. Нәтиҗәләр 15 февральдә ясалачак. Җиңүчеләрне затлы калфак һәм акчалата приз көтә, – ди Регина Хәкимҗанова.

Блогер әйтүенчә, язылучысының барысы да катнашмас, чөнки робагый язар өчен, тормышның агын да, карасын да күрергә, акыллы, фәлсәфи фикер йөртергә кирәк. Тик шулай да катнашырга теләүчеләр бар. Регина иң яхшы робагыйларны, язылучылары белән бергәләп, тавыш бирү нәтиҗәсендә билгеләячәк. Шулай гадел булыр дип саный. Бәйгедә ул халыкны үзебезнең тамырларны югалтмаска да өнди.

– Соңгысы булмас. Башымда кызыклы, файдалы фикерләр бик күп. Бары вакыт кына җитсен. Минем кебек үз милләтенең киләчәге өчен борчылучылар, теленә тугры калучылар күбрәк булсын иде, – ди Кукмара районы мәдәният йорты методисты Регина Хәкимҗанова.

НАИЛӘ ӘХМӘДИЕВА:

«ҖИРДӘ ЭШЛӘГӘН КЕШЕНЕҢ ХЕЗМӘТЕ БӘРӘКӘТЛЕ»

«Авылда да менә дигән итеп яшәп була!» Казаннан Апас районының Дәвеш авылына кайтып яши башлаган ирле-хатынлы Наилә һәм Азат Әхмәдиевләр әнә шулай ди. Без алар белән уңышка ирешү серләре турында сөйләштек.

«Авылда тормыш бик рәхәт»

Алар икесе дә Казанда туган. Тагын да төгәлрәк әйтсәк, Осиново һәм Залесный бистәләрендә. Биредә яшәгән вакытта ук теплицада суган үстерү белән шөгыльләнгәннәр.

– 2000 елда гаилә кордык. Тормыш итүебезнең беренче елларында төрле эшләр белән шөгыльләнеп карадым, тик аларның берсе дә күңелгә рәхәтлек бирмәде. 2005 елда, дусларыбыздан күреп, суган үстереп карарга булдык. Беренче вакытларда подвалда үстердек тә бер сезоннан соң теплица ясап куйдык, – дип искә ала ул елларны хуҗабикә.

2011 елда Дәвеш авылында әтиләренең мирас булып калган җирләрендә дә теплица эшләп куялар. Җәен акрынлап яшел тәмләткечләр дә үстерергә булалар.

– Яшел суган үстереп, аны «Бәхетле» кибетләр челтәренә тапшыра идек. Ләкин аларга тулы ассортимент (укроп, петрушка, кинза, базилик һәм башка яшел тәмләткечләр) кирәк булды. Мәскәү артында күпләп яшелчәләр, тәмләткечләр үстереп саталар. Ике ел без дә шулардан алып кайттык. Ләкин аларны үстергәндә, матур булсын һәм озак торсын өчен, ашлама күп кулланалар. Мәскәүдән Казанга кайтып җиткәнче, алар «яна», бозыла. Берничә тапкыр шундый хәл белән очрашкач, үзебезгә дә тәмләткечләр үстерә башларга кирәклеген аңладык, – ди Наилә ханым.

Баштагы елларда Казан белән авыл арасын шактый таптый гаилә. Язын-кышын суган, тәмләткечләр үстерәләр дә кышка Казанга кайтып китәләр. Ике арада йөреп арыгач, ике ел элек йорт салып, Дәвешкә бөтенләйгә кайтып төпләнгәннәр.

– Ике арада йөрү җиңел булмады. Әле өч балабыз да бар бит. Аларны мәктәпкә, балалар бакчасына йөртергә кирәк. Каенанама рәхмәт. Аның ярдәме булмаса, болай итеп эшли алмас идек. Миңа авылга күченеп кайту авыр бирелмәде. Барысы да ошый, тик әйләнә-тирәмдә күңелемә якын кешеләр булуы гына җитми. Кызганыч, авылда көнләшү, эшебезгә зыян китерү, аяк чалу кебек күренешләр белән очрашырга туры килде. Ә балаларга авылга чынлап торып ияләшергә кирәк булды. Аеруча улыбыз читенсенде. Казанга дәү әниләренә кунакка баргач, шәһәрдән китәсе килмичә елый иде. Ләкин тора-бара ул да авылны үз итте. Хәзер, киресенчә, авылга, өйгә кайтабыз, дип ашкынып тора, – ди эшмәкәр ханым.

Тырыш һәм булдыклы гаилә фикеренчә, эш булса, авылда да бик рәхәт итеп яшәргә мөмкин.

– Авылда бик рәхәт тормыш. Хәзер инде бу иркенлекне, саф һаваны, тынычлыкны, «бөке»сез тормышны Казанда яшәүгә алыштырасым килми. Башкалага эш буенча барырга туры килгәндә дә ыгы-зыгыдан, машиналарның күплегеннән, тар урамнардан арып, авылыма ашкынып кайтам. Авылдагы саф һава, экология дә бик ошый. Аннан соң, монда балалар өчен күңел тыныч, – ди ул.

«Татарстанда яшелчәгә ихтыяҗ зур»

Залесныйда торганда ук хәләл көчләре белән булдырган эшләренең бәрәкәте, авылга кайткач, тагын да арта. 2011 елда эшләрен 4 гектарда башлаган булсалар, бүген инде утырту мәйданнары 70 гектардан артып киткән. Киләчәктә тагын да арттыру планнары бар. Өч ел элек авылда 1200 квадрат метрлы җылы теплица да эшләп куйганнар. Бер гектар мәйданда тагын теплицалары бар.

Әхмәдиевләр гаиләсе кыш көне дә тик тормый. Кыш уртасында да теплицаларында яшел суган үстерә.

– Элек без башлы суганны Саратов, Волгоград өлкәләреннән алып кайттык. Ләкин алар бик үк сыйфатлы булмый торган иде. Я чери, яки үсеп китә алмады. Кирәкле сортны таптык тә инде өченче ел үзебезнекеләрне үстерәбез, – ди Наилә ханым.

Әңгәмәдәшем әйтүенчә, ачык һавадагы эшләр язын башлана. Башта башлы суган үстерер өчен орлык һәм яшел тәмләткечләр чәчәләр. Җәен яшел суганга дигәнен утырталар. Шунысы кызык: алар кыякка дигән суганны җир астына күмми. Уртача зурлыктагы башлы суганның тамыр чыгарган өлешен теплицалардагы махсус ясалган урынга, урталарында урын калдырмыйча, берәм-берәм тезеп чыгалар.

Наилә ханым әйтүенчә, суган кыягын 30–40 см озынлыкка җиткәч кисеп алалар. Моның өчен уртача 21 көн кирәк.

– Кышын теплицада яшел тәмләткечләр үстермибез, чөнки аның чыгымы күп. Ул үз-үзен акламый һәм сыйфаты да яхшы булмый. Үзкыйммәте 1000 сумга чыга. Ә хәзер базарда сатыла торган Үзбәкстаннан, Иораннан кайтарылганнарның килограммы 150–200 сум тора. Бәяләр аермасын үзегез чамалыйсыздыр...

Суганнан алынган табышка килгәндә, моңа соңгы өч елда гына ирешә башлаганнар. Эш башлаган елларда авыр булган, билгеле. Ләкин башлангыч чордагы авырлыкларны җиңгәннән соң, җиңеллек килә.

– Шуңа күрә мондый бизнеска алынгансыз икән, авырлыклар булуган карамастан, аны саклап калыр өчен тырышырга кирәк. Гомумән, җирдә эшләгән кешенең һәр хезмәте бәрәкәтле. Нәрсә генә үстерсәң дә. Миңа еш кына: «Наилә ханым, нәрсә үстерик икән?» – дип киңәш сорап киләләр. Андый кешеләргә: «Кыйммәтле продукция үстерегез. Мәсәлән, җиләк, брокколи, пекин кәбестәсе. Ә бәрәңге, кишер, суган ише яшелчәләрдән табыш алыр өчен аларны күпләп үстерергә кирәк. Аз гына үстереп, сизелерлек керем кертеп булмый», – дип җавап бирәм, – ди ул.

Наилә ханым сүзләренә караганда, җәен тәмләткечләр үстергәндә ике төп проблема бар. Аның берсе – су сиптерү. Икенчесе – чүп үләннәр белән көрәшү. Беренче проблеманы өстәмә чыгымнар белән хәл итеп булса, чүп үләннәр – авыррак.

– Узган җәйгә кадәр бер тапкыр да гербицид кулланган булмады. Бик күп кул хезмәте кирә иде. Узган ел беренче тапкыр сак кына, аз күләмдә үләннәргә каршы препаратлар файдаландык. Ә тәрбияләүгә килгәндә, яшел суган таләпчән түгел. Ул комда да, йомычкада да үсә ала. Аңа үсү өчен билгеле бер шартлар да кирәкми. 20–25 градус җылы, уртача дымлылык булса, шул җитә. Яшел суган яхшы үссен өчен бөтен файдалы матдәләре суганчаның башында бар, – ди ул.

Узган ел 40 гектардан 330 тонна башлы суган җыеп алганнар. Ләкин, җәй коры килгәнлектән, бу күрсәткечләрнең начар булуын әйтте эшмәкәр ханым. Гадәти елларда уңыш күләме ике тапкыр күбрәк була, ди. Шулай ук яшел тәмләткечләрнең уңышы да сөендерерлек булмаган: 36 тонна җыеп алганнар. Гадәттә, өч тапкыр күбрәк уңыш ала торган булганнар.

Әхмәдиевләр моңа кадәр бәрәңге дә үстергән. Ләкин узган ел туктатканнар, тик коры җәй бу эшне алга таба да дәвам итәргә кирәклеген күрсәткән. Шуңа күрә быел тагын бәрәңге чәчмәкче булалар.

– Моңа берничә сәбәп бар, – ди Наилә ханым. – Беренчедән, яшел тәмләткечләр үстерүдә көндәшлек зур. Алыпсатарлар бездән дә сатып ала, башка төбәкләрдән дә кайтарталар. Һәм кибетләр челтәренә сатып җибәрәләр. Ягъни безгә көндәшлек тудыралар. Ә яшел тәмләткечләр тиз бозыла, аларны озак саклап булмый. Шуңа күрә тәмләткечләр үстерә торган мәйданны арттыруның мәгънәсе юк. Икенчедән, Татарстанда бәрәңге, кишер, башлы суган, кәбестә ише яшелчәләргә ихтыяҗ зур. Ләкин бу юнәлешкә ныклап торып керер китәр өчен складлар төзергә кирәк. Менә шул юнәлештә эшләү теләгебез бар.

Тырыш һәм тәвәккәл Әхмәдиевләр гаиләсенә уңышлы эшләр телибез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Наилә ӘХМӘДИЕВА киңәшләре

➤Бер тапкыр яшел кыяк биргән суганнан икенче тапкыр уңыш алып булмый. Анысын черемә итеп куллансагыз яхшы. Искергән суганны җимеш агачлары (чия, карлыган, кура җиләге) төбенә тушәү аларны корткычлардан саклый.

➤Агач көлсәсенә кырмыска менмәгәч, гөблә дә булмый. Шуңа күрә чияләребез бик эре була безнең. Суганнан соң түтәлгә бакча җиләге, кыяр, ташкабак, кабак утыртырга киңәш итмим. Ә менә борыч, баклажан, помидор, кәбестә, киресенчә, суган җирен ярата.

➤Түтәлдә үсеп утыра торган башлы суганны кузгатырга ярамый. Культивацияләгән, араларын йомшарткан вакытта урынынннан кузгалган суган үсүдән туктый. Шуңа күрә аны тирәнрәк һәм сирәгрәк итеп утырту яхшы.

➤Җирне дә тәрбияләп торырга кирәк. Ул витаминнар, туклыклы матдәләргә туендырылган булырга тиеш.

➤Кайбакыт яшел тәмләткечләр, тармакланмыйча, өскә үсә. Моның сәбәбе югары температура яки су җитмәү булырга мөмкин.

➤Суганның иң файдалы өлеше – аның аксыл башы һәм 5–10 см кыягы. Ул өлеше витаминнарга аеруча бай. Ә очында файдалы матдәләр аз.

➤Кыякка дигән суганны орлыктан да чәчәргә мөмкин, ләкин ул катырак була. Ә менә суганчадан үстергән яшел кыяк тәмле, сусылрак була һәм шыгырдап тора.

АКЧАСЫ ДА ЮК, ҮЗЕ ДӘ...

АЛИМЕНТ ТҮЛӘРГӘ ТИЕШЛЕ КЕШЕЛӘРНЕ ЭЗЛӘП ТАБА АЛМЫЙЛАР

Гөлназ ике баласын ялгызы гына үстерә. Ире белән ике ел элек аерылышканнар. Баштарак хатын иреннән алимент алмаска уйлый. Ире дә: «Балалар белән очрашып торырмын, матди ярдәм күрсәтермен», – дигән. Тик ике тапкыр очрашудан соң, әти кеше югала. Биргән вәгъдәләрен дә үтәми. Гөлназга тормыш итү авырлаша. Алиментка гариза бирергә дип, документлар әзерли башлагач, аның беркайда да эшләмәве, үз исемендә милке булмавы ачыклана. Иң аянычы – ирнең кайда икәнлеге дә билгеле түгел. Гөлназ хәлендә калучылар шактый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Бала үстерер өчен акча кирәк. Аны ашату да, киендерү дә арзан түгел хәзер, – ди Чаллыда яшәүче Ләйсән Әхтәмова. – Ирем, ике балам белән калдырып, икенче хатынга чыгып китте. Ул хатынның ике баласын үстерә хәзер. Үзенекеләргә алиментны бик аз түли. Бер балага 3 мең сум акча килә. Белмим, аны ничек исәплиләрдер – иремнең хезмәт хакыннан чыгып санадык, диләр. Баштарак, бу акча нәрсәгә җитсен дигән идем, хәзер ризалаштым. Булмаганда ярап куя, – ди Ләйсән.

Балаңа алимент түләүләрен сорап, кая барырга? Аны ничек билгелиләр? Республикада баласына акча түләмичә йөрүчеләргә нинди чикләүләр куела? «ВТ» журналисты Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башкару производствосын оештыру бүлеге башлыгы Альберт Ибәтуллин белән сөйләште.

– Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре узган ел сабыена алимент түләмичә йөрүче 2955 кешегә административ беркетмә төзеде. 1103 кешегә карата җинаять эше ачылды, – ди ул. – Без иң беренче чиратта бурычлы кешеләрнең хезмәт хакыннан һәм банкта булган акчаларыннан әҗәтне тотып калабыз. Кайбер очракта бурычлы кешеләрнең шәхси милкенә арест салына. Әҗәтлеләрнең күчемле һәм күчемсез милекне теркәү, хәтта транспорт белән идарә итү хокукы да чикләнә.

Альберт Ибәтуллин әйтүенчә, бурычлы кешегә Россия чикләреннән чыгуны чикләү һәм мөлкәтенә арест салу – иң нәтиҗәле ысул.

– Алимент буенча бурычлары 10 мең сумнан артык булган очракта, суд приставлары кешенең чит илгә чыгу хокукын чикли. Кеше каядыр барырга җыенса, аңа бер атна алдан, суд приставлары идарәсенең рәсми сайтында яки хезмәтнең мобиль кушымтасында бурычлар булу яки булмавын тикшерергә киңәш итәбез. Күп очракта ул үз бурычын чит илгә чыкканда гына белә, – ди ул.

Бурычлының мөлкәтенә арест салу да уңай нәтиҗә бирә, ди суд приставы. Шуннан соң акча тиз табыла икән. Алимент түләмәүче йә акча табып түли, йә милке сатуга куела. Акчасы балага күчерелә. Республикада узган ел 2 мең кеше, алимент түләмәү сәбәпле, машина йөртү таныклыгыннан мәхрүм калган.

Күршебез Илшат, пандемия аркасында, эшендә кыскартылуга эләкте. Әле дә яңа эш урыны тапмаган. Үзеннән күбрәк әнисе өзгәләнә. Әтисе оныкка акча түли алмый, ди. Әгәр алимент түләргә тиешле кешенең эше юк икән, андыйлар мәшгульлек үзәгенә исәпкә басарга һәм алимент түләр өчен пособие алырга мөмкин. Әгәр түләмичә йөри икән, аңа карата административ беркетмә төзелә. 150 сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр яки 10–15 тәүлеккә административ арест каралган. Җавапка тартылган бурычлыларның күбесе бурычын түли башлый икән.

– Әгәр административ җәза билгеләнгәч тә, бурычлы кеше алимент түләүдән баш тартса, җинаять җаваплылыгы яный. Административ һәм җинаять җаваплылыгына тарту бурычлы кешене алимент түләүдән азат итми. Ул барыбер бурычлы булып кала, – ди Альберт Ибәтуллин.

Алиментны ничек исәплиләр соң? Бүлек башлыгы әйтүенчә, суд карарында йә билгеле бер сумма, йә айлык эш хакының дүрттән бер өлеше дип язылган була. Хезмәт хакының өчтән бер, алтыдан бер өлеше дә булырга мөмкин. Бу ничә бала булуга карый. Эшләмәүчеләр өчен бу сумма Россиядәге уртача хезмәт хакыннан чыгып исәпләнә, андый очракта кешеләрнең бурычлары күбрәк җыела, чөнки Россия буенча уртача хезмәт хакы Татарстандагыга караганда зуррак. Алиментлар күләме түләү турында килешү белән бурычлы кешенең хезмәт хакы яисә башка кереме күләменнән чыгып билгеләнә. Алимент күләмен үзгәртү өчен, түләттерүче як судка гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Гаиләнең матди хәлен игътибарга алып, суд аны йә арттыра, йә киметә ала.

Лаешта яшәүче Айгөл Сафина, иреннән аерылганнан соң, алиментка биреп тормаган. Дүрт ел узып киткән. Якыннары киңәше белән, ул иреннән хәзер алимент сорарга булган. Альберт Ибәтуллин аңлатуынча, Айгөл алдагы өч ел өчен алиментны түләттерергә мөмкин.

– Суд приставлары хезмәтенә алиментны түләттерү турында башкарма документ яки алиментны түләү турында нотариуста расланган килешү рәсмиләштерелгәннән соң мөрәҗәгать итәргә кирәк. Кулыгызда документларның төп нөсхәсе һәм акча күчерү өчен банк реквизитлары булсын, – ди ул.

Бурычлының кайда булырга мөмкинлеге һәм матди хәле турында мәгълүматны суд приставлары кабул итүгә килгәч яки язма рәвештә хәбәр итәргә мөмкин. Әгәр кеше беркайда да эшләми, мөлкәте дә юк икән, суд приставлары салым органнары, ЮХИДИ хезмәткәрләре белән берлектә аны эзләячәк.

Күпләр суд приставларының озак эшләвеннән зарлана. Баксаң, күп очракта алимент түләргә тиешле кешене эзләп, вакыт үтә икән. Әле шушы көннәрдә генә суд приставларына Казанда яшәүче бер ханым мөрәҗәгать иткән. Элеккеге ирен эзли башлаганнар. Аның Буа районында пропискада торуын ачыклаганнар. Әмма суд приставлары эзләп килгәч, туганнары ирнең алар белән яшәмәвен, читтә эшләвен әйткәннәр. Бу ирне әле дә эзлиләр. Шулай ук бу кешегә Россиядән чыгуга чикләү куйганнар, машина йөртү хокукын да чикләгәннәр.

Суд приставлары 2021 елда алимент түләмичә йөрүче 850 кешене эзләп тапкан. Кайберләренә җинаять эше ачылгач, күбесе акча түли башлаган. Узган ел сабыйларга 512 миллион сум алимент акчасын түләттергәннәр. Әгәр алимент түләргә тиешле кешедән бер ел эчендә бернинди хәбәр булмаса, баланың әтисе яки әнисе судка мөрәҗәгать итә ала. Суд әлеге кешене билгесез рәвештә югалган дип карар чыгара. Шуннан соң балага туендыручысын югалтканга пенсия билгеләнә.

2021 елның 30 декабрендә Россия Президенты Владимир Путин алиментны тулы күләмдә түләмәгән өчен җаваплылыкка кагылышлы законнар пакетын имзалады. Закон буенча Җинаять кодексының «Балаларга яки эшкә яраксыз әти-әнисенә алимент түләмәгән өчен» маддәсенә төзәтмәләр кертелә. Хәзер алимент түләмәүчегә бер елга кадәр ирегеннән мәхрүм итү яный. Ә менә бурычларын түләгән алиментчы җаваплылыктан азат ителәчәк. Моннан тыш, Россия Административ хокук бозулар кодексының 5.35.1 маддәсенә дә үзгәреш кертелде. Аның буенча ике ай дәвамында алимент түләмәгән кешегә төзәтү эшләре, 10–15 тәүлеккә кулга алу яки 20 мең сум күләмендә штраф яный.

Сан

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе матбугат үзәге хәбәр иткәнчә, Татарстанда алимент түләмичә йөрүче **19780** кеше бар. Шуларның **78** проценты – ирләр, **13** проценты – хатын-кызлар. **2,5** меңенең кайда яшәве бөтенләй билгеле түгел. **8,7** мең кешенең эш урыныннан алимент тотылып кала башлаган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЛИЛИЯ ГЫЙБАДУЛЛИНА:

«ШАГЫЙРЬЛЕКНЕ СОРАП АЛМЫЙЛАР»

Ул беркайчан да, менә мине күрегез, дип күкрәк киермәс, тавыш куптармас. Әмма сүзен әйтсә, берәгәйле әйтер. Соңгы вакытлардагы уңышының сере шунда түгелме икән? Шагыйрә Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА белән яшьләр иҗаты, хәзерге әдәбиятның проблемалары, аермасы, хатын-кыз шагыйрә булу үзенчәлекләре турында сөйләштек.

Лилия Гыйбадуллинаның шәхси архивыннан

:: Лилия, узган елгы уңышларың – әдәби конкурста берьюлы берничә номинациядә җиңү тормышыңа, иҗатыңа ничек тәэсир итте?
– Язганнарыңның кирәклеген тою бик рәхәт инде ул. Каләм иясе моңа һәрвакыт мохтаҗ. Бу җиңүләрнең иҗатыма тәэсире турында сөйләргә иртәрәк әле. Әмма шунысы хак: каләмемә ышанычым ныгыды. Ә үземә килгәндә, ул җиңүләрем үземнән битәр башкаларга күбрәк тәэсир итте кебек. Берара телефоным тынып тормады, берничә телевизион тапшыруга, әңгәмәләргә чакырдылар. Игътибар үзәгендә булырга яратмасам да, декабрьдә Чаллы – Казан арасын шактый таптарга туры килде.

Мин бәләкәйдән нәфис сүз ярышларында да, әдәби иҗат бәйгеләрендә дә, фән олимпиадаларында да, спорт ярышларында да катнашып үстем. Әйтик, мәктәптә укыганда ике ел рәттән татар әдәбиятыннан республика олимпиадасында беренче урын алдым. Бу миңа университетка юл ачты. Җиңү төмен дә, җаваплылыгының авырлыгын да тоеп үстем, кыскасы. Син әйткән бу әдәби бәйгегә дә гап-гади конкурс итеп карыйм. Татар әдәбиятын яңа әсәрләр белән баету, татар язучысын иҗатка кызыксындыру максатыннан шундый олы бәйге үткәрелү – әлбәттә, бик күңелле күренеш. Каләм әһелләрен берникадәр селкетеп алды кебек ул, катнашучылар да күп булган бит. Мин дә яздым һәм катнаштым – шул гына. Ә әдәбият ул ярыш мәйданы түгел.

:: Дусларың арттымы, дошманнарыңмы?
– Дусларым да артмады, дошманнарым да барлыкка килмәде. Мин якын күргән кешеләр җиңү-җиңелүләрем аркасында гына янымда булучылар түгел. Беркемне дә дошман күрмим, беркемнән дә дошман эзләмим. Кемдер мине өнәп бетерми икән – анысы инде минем проблема түгел.

:: Әле бит син – «Белла» Россия-Италия премиясе иясе дә.
– Әйе. 2015 елда – «Белла» премиясенә, узган ел «Кайту» дип исемләнгән китабым өчен Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премиягә ия булдым. Бу шагыйрьләр исемен йөрткән әдәби бүләкләргә лаек булу – минем өчен олы мәртәбә.

:: Балалар прозасында күптәнме син? Бирәдә эшләргә нәрсә мәҗбүр итә?
– Балалар һәм яшүсмерләр өчен яза башлавым «Көмеш кыңгырау» газетасы белән бәйле. Әлеге басмада берничә ел эшләдем. Төрле мәктәпләрдә очрашуларда булып, балалар язган хатларны, шигырьләрне, язмаларны укып, аларны бераз аңлый башладым кебек. Үземнең дә ике улым үсеп килә. Балалар өчен язганда, беренче чиратта, аларны куз уңында тотам. Әдәби әсәрләр конкурсына җибәргән повесть та олы улым Ильяс өчен язылды. Кып-кыска җөмләләр белән, сурәтләүләргә, лирик чигенешләргә, дидактикага мөмкин кадәр азрак урын биреп, үземне шактый тыеп яздым мин аны.

Хәзер мәктәпләрдә укыту русча, урамда – рус мохите. Мәктәп китапханәсендә татар китаплары юк дәрәҗәсендә. Казанга баргач, китап кибетенә керми калмыйм. Әмма хәзерге балаларны кызыксындырырлык татарча китаплар бик аз. Ә бит татар китабын укытасы килә. Проблема татар әдәбиятында гына түгел, проблема – балаларда да. Татар балалар һәм үсмерләр әдәбияты бүген татарча ярым-йортлы гына белә торган һәм кулында смартфон, гаджеты булган бичара татар баласына яраклашырга мәҗбүр. Гади, җиңел тел белән язылган, акыл сатуларны читкәрәк куеп торган, мавыктыргыч сюжетлы әсәрләр – балаларыбызны үзебезнеке итеп, телле итеп саклар-лык, татар теленә һәм әдәбиятына кызыксыну уятырлык әсәрләр кирәге көн кебек ачык.

:: Өлкән буыннан яшьләр иҗатын аңламыйбыз, алар бүтәнчә яза, дигәнне еш ишеткән бар. Моның сәбәпләре нәрсәдә? Өлкәннәрнең артта калуындамы, яшьләрнең, үткәннәрдән өзелеп, «европача» иҗат итәргә тырышуындамы? Әллә проблема бөтенләй дә юкмы?
– Яшьләрнең артта калуында, дисәм инде… Узгынчы әйбер ул. Куып тотарлар әле. Элек тә шулай булган, киләчәктә дә шулай булачак. Булсын. Картлар да аңларлык икән, нәрсәсе кызык инде ул яшьлекнең!

:: Чаллы язучылары үзгә. Моны аңлар өчен Фәүзия Бәйрәмова, Айдар Хәлим, Факил Сафин исемнәрен атау да җитәдер. Бу төбәкнең көче нәрсәдә?
– Чаллы язучылары дип аермас идем мин. Чаллыда яшәүче татар язучылары диик. Әйе, Чаллы – үзенчәлекле шәһәр. Ул миңа гадилеге һәм гаделлеге белән кадерле. Хезмәтләре таудай булса да, бернинди пафоссыз яшәүче, иҗатны намус эше дип кабул иткән, заводларда, тимер-таш арасында эшләп тә, әдәбиятка тугры калган язучылар бар биредә. Кирәк чакта үсендерә, кирәк чакта тәнкыйть сүзен күзеңә карап әйтә торган өлкән каләмдәш-дуслар таптым монда. Чаллыда җылы, ихлас әдәби мохит бар. Шул мохитне саклап торучы Факил абыйга рәхмәт.

:: Яшь язучыга китап чыгару, аны укучыга җиткерү авырмы? Зифа апа Кадыйрова кебек, үзең авылдан-авылга йөрү, укучылар белән очрашу актуальме әле?
– Ничек китап чыгарыйм икән, дип бервакытта да хәсрәтләнгәнем булмады. Беренче китабымны Рәдиф Гаташның нәшриятка җыеп биргәнен, ул китапның чыкканын белми дә калдым. 17 яшем тулган көнне үземә почта конвертында килеп җитте ул. Бүгенгә җыйнак кына дүрт шигъри җыентыгым бар. «Сөрән» дигән китабым узган ел дөнья күрде. Гонорар хисабына 170 данәсен үземә бирделәр. Сораучыларга почта аша җибәрәм. Китап тарату максаты белән очрашулар оештырганым юк. Дөресен әйткәндә, моңа вакытым да юк. Андый язучыларга хөрмәтем зур. Әлбәттә, очрашуга чакырсалар, барырга тырышам. Һәм күп очракта халыкның шигърьгә сусавын, әдәбиятка битараф булмавын тоеп, берникадәр гаҗәпләнеп тә кайтам әле.

> Хәзер без бик ялкауландык бит: әйберне кулыбызга китереп тоттырганны көтеп ятабыз. Өй янындагы азык-төлек кибетенә дә чыкмыйбыз ич, кешедән китертәбез. Бу пандемия зәхмәте чорында отыры шуңа ияләштек. Китапка да мөнәсәбәт шулай кебек. Кешенең кулына китереп тоттырсаң, ул аны сатып та ала, укый да. Үзе кибеткә чыгып алмый менә. Хәер, кайда гына бар соң ул татар китабы кибетләре…

:: Шигърият нинди холыкны ярата?
– Шигърият – сагыш ул. Мәхәббәт тә түгел, бәхет тә түгел, шигырь – гомерлек сагыш ул, минемчә. Аннан котылып булмыйдыр. Шагыйрьлекне сорап алмыйлар, ул – язмыш. Күңел сизгерлеге, әйтелмәгән сүзләрне дә ишетү, тоярга тиеш булмаганны да тоеп яшәү җәзасы да ул. Бәхетле шагыйрьләр булмый. Шигырь – яра да, дәва да. Шигърият үз рухыңа, күңеләңә сак караганны, бөтенлекне, үз-үзең белән гармонияне ярата. Бу сүзне безнеңчә җан тынычлыгы диләр бугай. Олыгайган саен, җенемә туры килмәгән кешеләрдән, күңелемдә резонанс тудырырдай вакыйга-урыннардан читтәрәк йөрергә тырышам. Тагын шунысы да бар: шигърият үзеннән дан-дәрәҗә эзләүчеләрне өнәми, кача. Үзенә саксыз кагылганны, кадерсезләүне дә кичермидер ул.

:: Ркаил Зәйдулланың «Хатын-кызга шигърияттә авыр, чөнки шигърият гаиләгә, балаларга да игътибар бирүне яратмый, ул көнчел» дигән фикере бар. Килешәсеңме?

Блиц-сораштыру

– Иң зур теләгең?
– Балаларым, оныкларым – нәселем киләчәгенең иминлеге, рухи саулыгы.
– Өстәл китабың?
– Һәрвакыт төрле. Бүген Ләис Зөлкарнәйнең «Узганны кабатлау» китабы.
– Синең өчен иҗат – ...
– дәва.
– Шушы мизгелдә күңелеңдә яралган шигъри юллар?
Офыкларда яз сискәнеп куйды,
Күңелемә кунды вакыт сере...

– Бәлки Ркаил абый хаклыдыр. Кияүгә чыктымы – шагыйрь «үлә», дигән сүзне берничә ир-ат язучыдан ишеткәнем булды. Заманында ышандым да кебек мин бу фикергә. Кияүгә чыкканда, башка язмам шикелле иде. Яңәсе, шигырь – яшьлек романтикасы, шуның белән вәссәлам. Аннан бер-бер артлы ике малай алып кайттым. Һәм чынлап та 5–6 ел берни дә язмадым. Әмма берзаман, балалар итәктән төшкәч, күпмедер буш вакыт барлыкка килгәч, китапханәгә киттем. Чаллыда яшәүче язучыларның иҗаты белән таныша башладым, китап укырга тотындым. Аннан «Кайту» шигыре язылды...

Мин төрле була алам. Миндә әллә ничә «мин» яши. Бу төрлелекнең сәбәпләре балачактан ук, мөгаен. Чагыштырмача иртә яза башлап, бик яшьли олпат каләм ияләреннән хуплау сүзләре ишетсәм дә, гаиләдә хуплау күреп үсмәдем мин. Бик яшьли китабым чыгу да безнең өйдә вакыйга саналмады. Әти «язма» дип кистереп әйтмәсә дә, иҗат юлына каерулымны хуплап бетермәгәнен тоеп үстем. Мин аны һич гаепләмим. Киресенчә, рәхмәтлемен. Нәкъ шундый кырыс тәрбия мине бүгенгәчә шагыйрь итеп саклады. Бәләкәйдән төрлеләнергә, кирәк чакта коры реалист булырга, кирәк чакта шигырьне иреккә чыгарырга өйрәнгәнмен, ахры, мин. Тормышта да «шагыйрьә» булып яшәсәм, янып беткән идем инде...

Менә болайрак аңлатып карыйм әле. Миндә кимендә ике «мин» яши – ир хатыны, ике ул әнисе Сираева һәм язучы Гыйбадуллина. Мин аларны йөгәнли беләм. Талаштырмыйм, алар дус яшиләр. Хәтта бер-берсенә булышалар, бер-берсен тулыландыралар да. Әмма гаиләм – минем өчен һәрвакыт беренче урында. Үземне дөрес яшим һәм кыйммәтләрне дөрес билгеләгәнмен дип уйлыйм. Ихтимал, ирем мине бөтен барлыгым белән кабул итмәсә, аңламаса һәм теге Гыйбадуллинаны танымаса, миңа бик авыр булыр иде. Бәхеткә, ул – бик акыллы һәм сизгер кеше. Ул – иҗат өчен шартлар булдыручым, тылым.

:: Ә шигырь кайчан языла?
– Гадәттә, төнлә. Кайвакыт көндез дә. Кайчан күңелемә дәшеп китерәм – шунда языла ул шигырь. Ул бит минем каләм тотуымны сагынып килә.

:: Хәзерге заманга нинди бәя бирер идең? Без нинди заманда яшибез?
– Без нинди дер күпердән барабыз кебек тоела миңа. Менә өзеләм, дип чайкалып торган асылмалы күпердән. Аргы яктан биргә якка үтеп чыгарга гына кирәк нибары. Сакланырга, исән калырга кирәк. Бу тар күперне бервакыт барыбер чыгарбыз. Дөнья гел болай гына бармас ул. Безгә исә бүген телебезне, динебезне, канызбызны, милләтебезне, әдәбиятыбызны сакларга, киләчәккә кадәр илтеп җиткерергә кирәк. Кешене өмет яшәтә. Мин киләчәгебезгә ышанам. Ышанмасам, үземә һәм сүземә ышанмыйм дигән сүз.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

РАВИЛӘ ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ

ЯЛАНТАУГА АЙ КУНГАН (БӘЯН)

< Дәвамы. Башы 2021 елның 10 декабрь, быелның 21, 28 гыйнвар, 4 февраль саннарында

– Апа ник килгән ул?

Рәфыйкның бите киселгәнгә, малайларның сугышканнарын ишеткәнгә килгән дип коты очкан иде Сәетнең.

– Улым, менә апаң сиңа кәчтүм-чалбар, каеш, кепка, аяк киеме китергән. Киеп кара әле.

Ятьмә букчадан чыккан киемнәрне күреп, малайның һушы китте. Алар өр-яңа иде. Зариф карт та, укытучының, боларга уңайсыз булмасын өчен, улымнан калган киемнәр дип алдаганын аңлап алды.

Сәет ашыга-ашыга киемнәрне киде дә көзгегә карады. Чебен чуарлап бетергән көзгедән шундый да матур малай карап тора иде.

– Матур бит, бабай, әйеме?!

– Матур, улым, җылы тәнеңдә тузсын, балакаем. Апаңның бу яхшылыгын бер дә онытма. Яхшылыкны оныткан кеше игелек күрми ул.

– Ярар, бабай, – диде Сәет, – онытмам!

Сәет иртәнә җиткерә алмыйча интекте. Иртән, матур киемнәрен киеп, мәктәпкә китте. Ботинкаларны бабасы, язга кияреусең, улым, дип җыеп куйды. Класста Рәфыйк күренмәде. Укытучының да күңеле төшенке. Укучылар белән дә елмаймыйча, коры гына исәнләште. Сәетнең йөрәгә дерт итеп куйды. Рәфыйкка берәр нәрсә булганмы әллә? Шунда класска дулый-дулый Рәфыйкның анасы килеп керде дә керә-керешкә Сәет өстенә ташланды.

– Ах син, хәерче калдыгы, үләксә! Минем улымның битен умырып төшергәнсең. Врачлар бүген тегеп кайтарганнар. Шәмәхә карасы тәненә сеңеп, мәңгелеккә ямьсезләнеп каласы ди. Инсаф кына кайтсын, буып үтерә үзеңне, кабахәт, – дип, малайны уңлы-суллы яңаклый башлады. Укытучы килеп җитмәгән булса, Сәет нишләгән булыр иде? Бала нәни куллары белән битен капламакчы була, ә сәер апа аны, парта арасыннан йолкып чыгарып, ишеккә таба өстери иде. Яңа кәчтүмнең төймәләре тукымасы белән бергә умырылып чыкты.

«Айгыр» кушаматлы Маһинур кулында Сәет бәләк сыман бәргәләнде. Укытучы тиз генә Сәетне йолып алды да үзе белән ышыклады.

Айгыр Маһинур укытучыга ташланды.

– Кем икәнемне беләсең, Нурания, яклама аны. Бүре баласы ич ул. Бетергән бит улымны, имгәткән, – дип, үкереп еларга тотынды хатын.

Нурания аңа су алып килеп бирде.

– Тынычлан, Маһинур, бәлки әле, әйбәт булыр. Алдан алай бетеренмә. Сәет бер дә начар малайга охшамаган. Рәфыйк үзе Сәеткә гел бәйләнеп тора. Күрәм ич мин. Ник ятимне шулай рәнҗетәсең? Ходайдан оял!

– Әле син, авызыңны тутырып, Ходай дип торасыңмы? Күрсәтермен мин сиңа Ходайны! Иртәгә үк язып бирәм кәнсәләргә. Директорыңа да хәбәр итәм. Сине мәктәптән буклы пумала белән куарга кирәк, – дип дулап, хатын директор кабинетына юнәлде.

Нурания куркынган балаларны тынычландырып, урыннарына утыртты:

– Ягез, тынычланыгыз, балалар. Менә күрдегезме нинди күңелсез хәл килеп чыкты. Күңелегезгә салып куегыз, балалар. Кеше кычкыра дип, сез дә кызып китеп, алай тавышланмагыз, югыйсә шул кеше дәрәҗәсенә төшәрсез. Намусны бер югалтсаң, табуы, ай-һай, бик читен булыр.

Шунда Гөлҗиһан торып басты:

– Апа, – диде ул, күз яшьләрен сөртә-сөртә. – Сезне хәзер, «Ходай» дип әйткән өчен, эштән алалармы инде? Апа, син андый сүзне әйтмәдең ич, без ишетмәдек, име, кызлар, әйтмәде бит, име, малайлар?

Төрле яктан «юк, юк, ишетмәдек» дигән сүзләр ишетелде. Укытучының күзләренә яшь килде. Кара әле бу балаларны. Алар бит апаларының кача-кача Корьән аятьләре укуын, ураза тотарга тырышуын белмиләр. Җаны-тәне белән Аллага ышана бит ул. Әти-әниләре дә намазларын калдырмады, ураза тотты. Гает намазын картлар, кача-поса, таш келәттә укыйлар. Бөтен авыл халкына хәер-дога кылып торалар ич. Ә берсендә, өйләренә мәктәп директоры белән колхоз председателе килеп кереп, әтиләрен намазның өстендә тотып, икенче көнне халыкны клубка җыйдылар. Авылда дин сөремен таратучы дип гаепләп алып киттеләр әтисен. Бәхилләшеп чыгып киткәндә, җиде бала әтиләренә килеп асылынды.

– Әниегезне тыңлагыз! Нәселгә тап төшермәгез! Ничек булса да үсәрсез. Укырга тырышыгыз! Безнең нәсел математика фәненә хирыс...

Балалар әтиләренең кечерәеп, бөкрәеп калган гәүдәсен клуб тыкрыгына кереп югалганчы карап калдылар.

Клубта районнан килгән вәкил дә бар иде.

Габделхәйне беренче рәттәге артсыз урындыкка утырттылар. Сәхнәдә – мәктәп директоры, теге вәкил һәм колхоз председателе.

Диннең – агу, Габделхәйнең дошман икәнлеген, аның ише кешеләрнең авылда яшәргә хакы юклыгын, урыны төрмә булганлыгын озак аңлаттылар халыкка. Габделхәй алар сөйләгән сүзләрне аңларлык хәлдә түгел иде. Хатыны җиде бала белән кала, балалары яшь... Нишләр ул? Миңа кайтулар юк инде, дип уйланып утырды Габделхәй.

Арыган вәкил мәсьәләне кабыргасы белән куйды:

– Кем дә кем Габделхәйне районга җибәреп тикшертергә, башын төрмәдә черетергә ди, кулларыгызны күтәрегез. – Клубта үлем тынлыгы урнашты. Шулай да бер-ике бирчәеп беткән кул күтәрелде. – Активрак булыгыз! Йокладыгызмы әллә анда? Үзегезнең дә китәсегез киләме? – дип, өстәлгә сукты вәкил.

Шунда акрын гына бер хатын-кыз тавышы ишетелде:

– Габделхәйне алып киткәч, безнең казан төбен кем ямар суң, комганнарыбызны кем ямап бирер, кем безнең уракларыбызны тешләр?

Шул бер җөмлә җитте халыкка.

– Габделхәйсез кем сәгатьләребезне төзәтер?

– Ипи-тоз бетсә дә, шуннан алып торабыз.

Шау-шу купты. Авылның карап торган бер Габделхәе бит ул. Халык гөж килде.

– Не имеешь права, укыса соң, урамга чыгып укымый ич ул намазын. Өйдә генә укый. Аракы эчми, тәмәке тартмый, балалары тәүфыйклы.

– Кагылмагыз Габделхәйгә. Үстерсен балаларын. Инде Сталин вакытында да ярты авылны бетердегез.

Вәкил халыкны туктата алмады. Шунда Галиулла карт күтәрелде. Вәкарь белән сүзен башлады:

– Менә утырттык ди без Габделхәйне, алда язгы чәчү тора. Әйт әле, персидәтел, синең чәчкечләреңне кем төзәтер? Бер кешең дә юк бит. Үзең төзәтсәң генә инде. Габделхәйсез нишләрбез? Ул бит – бөтен тирә-як авылларга бер Габделхәй. Әйт әле, син язгы чәчүгә гатавайммы? Габделхәйсез нишләрбез? – дип кабатлады Галиулла.

Персидәтел дәшмәде.

Авыл халкы аннан да яманрак шаулаша башлады:

– Җибәрмибез, тимәгез безнең Габделхәйгә. Ул нәләт төшкән Шәрәфинең дә әләкләп туясы булмады.

Әтисе исемен ишеткән Инсаф дерт итеп китте. Өстәлгә китереп сукты.

– Җиттегез, Себер китәсегез киләме? Кайсыгыз әйтте бу сүзне? Халык шым булды.

Сәхнәдә утырганнар үзара киңәштеләр дә Габделхәйгә сүз бирделәр:

– Әйт, Габделхәй, башка намаз укымам, ураза тотмам, качып, гает намазы укымам, дип әйт, өеңә кайтасың килсә!

Габделхәй торып басты. Авыр итеп сулады да юаш бер тавыш белән акрын гына:

– Ярар, – диде.

Аның күзләрендә яшь тамчылары ялтырады. Үзе авылдашлары каршында гөрнадир кебек гәүдәсе белән елап торуыннан оялды. Тик бу күз яшьләрендә авыл халкына булган рәхмәте күбрәк иде.

Шул хәлләрне күз алдына китерде укытучы. Әнә ишек артында Маһинурның мәктәп директорына тәтелди-тәтелди сөйләп килүе, шыгырдап класс ишеге ачылуы ишетелде. Болай да каракучкыл йөзе тагын да каралып киткән директор артыннан Маһинур килеп керде. Балалар торып бастылар.

– Әнә балалар алдында миңа, Ходайдан оял, дип әйтеп тора. Әнә ул балаларны боза инде. Аңа мәктәптә урын юк. Атасы да мулла булып йөрде, – дип тезде Маһинур.

– Бу ни бу, Нурания Габдулхаевна? Бу сүзләр дөресме? – диде директор. Йөзендә боз салкынлыгы иде. – Балалар алдында шул сүзләрне әйттегезме?

– Туктагыз әле, бу балалар алдында хәл итәлә торган мәсьәлә түгел. Әйдәгез, сезнең кабинетка кереп сөйләшик.

– Юк, Маһинур хаклы, балалар алдында хәл итәбез. Балалар, әйттеме апагыз бу сүзне?

Чая Гөлҗиһан торып басты:

– Юк, абый, әйтмәде. Маһинур апа үзе Сәетне кыйнады, минем малайның битен җырткансың, дип. Мин үзем күреп торганыем. Кичә Рәфыйк Сәетне төртеп екты да әченә типте. Син хәерче, атаң мине ярата, дип. Кара савыты ватылды да, Рәфыйк таеп китеп, кара савыты өстенә егылды. Бите канады. Сәет тик кенә торганые. Аның гаебе юк, абый.

Дәвамы бар >

Язучы фикере



Марат КӘБИРОВ

Тагын Аллага шөкер

Чирнең берсе дә әйбәт түгел инде, әмма үзеңә килгәненннән дә хәтәррәге юк. Чөнки ул сине интектерә. Көне буе сызланып йөрисең. Әллә кайларга барасың бар, дүрт тарафтан кырык төрле эшең көтеп тора. Син аларның берсен дә булдыра алмыйсың – чир караватт тирәсенә бәйләп куйган. Шуңа эчең поша.

«Бу адәм бик эч пошырып йөрмәсен әле», – дигәндәй, авыруың синең шул мәшәкатьләреңне оныттырырга тырыша, берәр җиреңнән тешләп ала да үзәгеңә үткәреп сызландыра. Авыртуны баса торган дарулар эчеп карыйсың – файдасы тими. Әллә нинди сәер авырту ул: авырткан җиреңне тотып, шул урынга басып карыйсың – авыртмаган кебек. Аягың сынса яки берәр җирең шешеп чыкса, тәгаен беләсең бит инде. Тәнеңә кул да тидереп булмый. Ә бу бөтенләй башка төрле. Голограмма кебек. Барлыгы хак, берлеге хак – кулга тими, күзгә күренми. Кайчагында чир синең тәнеңдә түгел, ә баш мие белән бәйледер кебек тоела. Кайбер кешеләрнең аякларын кисәләр бит әле. Менә шуннан соң тегеләрнең аягы я сызлый, я үзәккә үтеп кычыта икән. Болар шул авырткан яки кычыткан урыннарын уып карарга дип үрелә… Ә ул урын юк… Кисеп алынган… Синең авыртуың да менә шуңа охшашрак. Әйтик, тез буының үзәгеңә үтеп сызлый, ә тоткалап карый башласаң, бер җире дә авыртмаган кебек. Шуңа күрә бер дару да ярдәм итми. Табиблар да диагноз куя алмый җәфалана. Бөтен җиреңне тикшереп чыгарга мәҗбүр булалар. Ә син аңынчы авыртудан тилмереп ятасың.

Көнозын шулай җәфалагач, төнлә ул чир үзе дә арып туктарга тиеш бит инде. Сине бераз ял иттерергә тиеш. Юк. Ул төн буе интектерә. Таңга кадәр шулай караватыңда боргаланып чыгасың да, кояш күтәрелү белән, хастаханә коридоры буйлап йөренергә тотынасың. Йөрсәң, хәл әйбәтрәк кебек.

Менә шунда башка авыруларны очратасың. Кайсы култык таягы белән боларның. Кайсы пакет белән шланглар сузылган шешәләр күтәреп йөри. Кайсы – инвалид коляскасында. «Бүген дә төн буе йоклый алмадым», – дип, үз зарыңны сөйләргә телең кычытып тора инде. Чирле кеше шулай була бит ул, үз җәфасын кешегә сөйләсә, авырулары кимеп, абруе артып китәрдәй тоела. Ләкин тегеләрне күргәч, телеңне тыярга мәҗбүр буласың.

Әнә берәү култык таягы белән китеп бара. Уң тезен күкрәгенә тиярлек итеп күтәргән, аяк очы кәкрәйгән, бармаклары бармагына өелеп катып калган. Паралич суккан моны. Бер бармагын кисеп ялгаганнар. Аягын төзәтү өчен, әле тагын әллә ничә операция ясарга кирәк икән. Уңышлы чыгамы алар, юкмы – билгесез. Хәтта уңышлы чыккан очракта да өр-яңадан йөрергә өйрәнергә туры киләчәк икән…

Әнә тегендәрәк бөкрәебрәк атлаган абзыйның бер бөерен алганнар. Икенчесен ясалма аппараткамы шунда, нәрсәгәдер тоташтырырга кирәк икән. Уңышлы очракта да ул кече йомышын шланг аша башкарып йөрергә мәҗбүр булачак.

Эскәмиядә моңсу гына утырып торган берәүнең тез буыннарына протез куйганнар. Аны ел саен алыштырып торырга кирәк. Авыр эш эшләргә ярамый, ашыгып йөрергә ярамый, тозлы-борычлы ашарга ярамый, борчылырга ярамый… Тагын әллә күпме «ярамый»лары бар… Читтән караганда ничава кебек күренсә дә, тормышы әнә шундый тыюлар белән тулы икән.

Һи-и-ии… Бер генә таза кеше дә юк инде бу авырулар арасында. Барысының да хәле – кыл өстендә. Менә шуларны күрәсең дә үзеңнең көн-төн сызлап тынгылык бирмәгән аяк-кулларыңны сыпырып куясың: «Аллага шөкер!»

Аллага шөкер шул. Ничек кенә сызланма, әле синең хәлең бөтенләй үк өметсез түгел. Авыртуларыңның кайсыдыр узар, кайсынадыр күнегергә туры килер. Һәрхәлдә, бер хәрәкәтсез урын өстендә яту да, аксаклап йөрү дә, протез өстендә яшәү дә, шланг аша печ итү дә көтми. Шулай булгач, ничек шөкер итмисең ди инде! Янәшәңдә коточкыч язмышка дучар кешеләр булганда, зарлану турында уйлау да оятсызлык кебек тоела. Ә алар бар. Гомумән… Нинди генә авыр хәлгә төшсәң дә, синнән дә начаррак шартларда яшәүчеләр була. Нинди генә әйбәт тормышка ирешсәң дә, синнән яхшырак яшәүчеләр табыла. Дөнья бу.

Ә тормышыңнан канәгать булып, Аллага шөкер итү өчен күп кирәкми, үзеңнән дә авыррак язмышка дучар булганнарны күрү дә җитә.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru



Рәис Габдулла

4 февраль санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: шарлах, чакрым, кын, Уен, терлек, Азат, мут, пат, Шота, Нуаре,Туан, арка, Ася, саламандра, Адур, Оле, Дион. **Вертикаль буенча:** кап, Натс, ахак, зарур, кытат, акыл, лорнет, эра, ама, хамелеон, Садри, Таяну, укмашу, дрон, авыр, нитрон, Алек.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Мулланур Вахитов ул – ...
А. «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәре авторы.
Б. Опера җырчысы.
В. Сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе.

2 Ромашкино нефть ятмалары кайсы елда ачыла?
А. 1999.
Б. 1948.
В. 2000.

3 Монголларның Төньяк Кытайны яулап алуы ничәнче елда була?
А. 1381.
Б. 1800.
В. 1211.

4 «Һәрбер эшләр көннән-көнгә китсен алга,
Муафикъ тарыз илә бу заманга.
Файдалы эш вөҗүдкә чыксын дисәк,
Карап яту тиеш түгел мөселманга».
Бу шигырь юллары кемнеке?
А. Мәҗит Гафури.
Б. Габдулла Тукай.
В. Шиһабетдин Мәрҗани.

Җаваплар: 1) В; 2) Б; 3) В; 4) А.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 17126 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 220

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+